4. The works of the third generation poets – M. Nazirov, M. Zakirov, S. Rakhmatullina – give us every reason to conclude that Tatar poetry in Bashkortostan was fully formed in terms of ideological and aesthetic content, its trends and style of the literary region, it constituted a powerful stream in the composition of Tatar poetry. The expressive-lyrical style, which reflects the synthesis of the cult of nature qualities, strict realism and romanticism, determines the main features of the folk, dynamically developing poetry of this generation.

5. The poets of the fourth generation – N. Aminova, L. Sagidullina, M. Vafin – are distinguished by the use of a variety of styles, philosophical and associative content, metaphors. These authors sparingly use thoughtful words, epithets, but at the same time they are able to put a deep philosophical meaning into a short verse.

Their poetic works, along with a synthesis of the poetic traditions of East and West, are based on national folklore, the poetry of the Tatar people. This is manifested in the transition of poetic images, motifs, means of depiction. At the same time, basically, the motif of being "with a language, but without it, in a country, but without it" in the Tatar poetry of Bashkortostan is at the highest level of its development.

## Conclusion

It should be noted that in Bashkortostan there are talented literary forces and spiritual and cultural traditions. The poets and their creative trends are different. However, all their melodies share the same Tatar motif. This melody takes its origin in the work of Shamsutdin Zaki, Akmulla, Dardemdam, Shaehzade Babich, Sagit Ramiev, Gabdulla Tukay, Mazit Gafuri and reaches our days through the work of Atnabay and N. Nazmi. Nationality, deep philosophy, harmony of feelings and thoughts are its main features. Of course, our poets create various works by genre, themes and style, posing and resolving arising issues. But there is one feature that unites everyone in their desire to create a new world model through imaginative thinking, their original attitude to life. In certain periods of time, social and political winds separate creative personalities from each other, but local poetry is an inseparable spiritual and cultural heritage and an achievement of the Tatar people.

**References**

1. Vafin, M., Khafizov, S. (2001). *Muza rodnoi zemli: kruglyi stol o tvorchestve poehtov, zhivushchikh v Bashkortastane* [Muse of the Native Land: A Round Table on the Work of the Poets Living in Bashkortastan]. Tulpar. No.1 (40), pp. 23–29. (In Russian)

2. Vahapova, L. (2013). *Sovremennaya tatarskaya literatura v Bashkortastane* [Contemporary Tatar Literature in Bashkortostan]. Nastoyashchee dostoyanie. No. 5 (17), pp. 103–110. (In Russian)

3. Nazmi, N. (2011). *Narodnaya dusha: stat'i, vospominaniya, pis'ma, stikhi, poehma* [The Soul of People: Articles, Memoirs, Letters, Verses and a Poem]. Avtor idei i sozdatel' R. Miңnullin. 479 p. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Russian)

4. Atnabaev, A. (1993). *Stikhi, poehmy* [Verses and Poems]. 192 p. Ufa. (In Russian)

5. *Atnabai. Narodnyi poeht* (2000) [Atanbay. The Peole's Poet]. 400 p. Ufa, Respublikasy Bashkortstan, fond "Rukhiyat". (In Russian)

6. Gabderakhim, F. (2015). *Kak tsvety: stikhi* [Like Flowers: Verses]. 157 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

7. Idiyatullin, R. (2007). *Dobryi vecher!: stikhi, korotuie dramy, rasskazy* [Good Evening!: Verses, Short Plays, Stories]. Sostavitel' i avtor zaklyuchitel'nykh slov R. Miңnullin. 271 p. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Russian)

8. Gataullin, R. (2008). *Pechal'nye melodii: stikhi* [Sad Melodies: Verses]. Sostavitel' Rafit i Radif Gataulliny; avtor vvodnykh slov R. Miңnullin. 223 p. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Russian)

9. Mudarisova, Kh. (1995). *Proshlogodnyaya osen': stikhi* [Last Year's Autumn: Verses]. Avtor vvodnykh slov N. Nazmi. 80 p. Ufa, Bashkort. knizhn. izd. (In Russian)

10. Mudarisova, Kh. (2003). *Fioletovaya noch': stikhi* [The Purple Night: Verses]. Avtor vvodnykh slov R. Gatash. 126 p. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Russian)

11. Mudarisova, Kh. (1982). *Serebryanaya podkova: stikhi* [The Silver Hoof: Verses]. 157 p. Ufa, Bashҡort. knizhn. izd. (In Russian)

12. Nvzirov, M. (1994). *Snova vkhozhu v ogni: stikhi, pesni, poehma* [Again I Enter Fires: Verses, Songs and a Poem]. 144 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

13. Zakirov, M. (2005). *Ptitsa, sevshaya na sech': stikhi* [The Bird Sitting on the Stove: Verses]. Avtor vvodnykh slov R. Timershin. 176 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

14. Zakirov, M. (1992). *Sama po sebe zatyanuvshayasya rana: stikhi* [The Wound Healing All by Itself: Verses]. 124 p. Ufa. (In Russian)

15. Rakhmatulla, S. (1993). *Probuzhdenie: stikhi, pesni, poehmy* [Awakening: Verses, Songs, Poems]. Avtor zaklyuchitel'nykh slov M. Vafin. 212 p. Ufa. (In Russian)

16. Rakhmatulla, S. (2001). Dazhe esli vody budut tech' v prtivopolozhnom napravlenii: stikhi, poehmy, chastushki, ehpigrammy, perevody [Even if the Waters Flow in the Opposite Direction: Poems, Poems, Ditties, Epigrams, Translations]. 240 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

17. Amineva, N. (2011). *Pod ruku s utrennim vetrom: stikhi, poehma, stsenarii, skazki* [Hand in Hand with the Morning Wind: Poems, Poems, Scripts, Fairy Tales]. 277 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

18. Sagidullina, L. (2004). *Sozvezdie momentov: stikhi* [A Galaxy of Moments: Verses]. 112 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

19. Vafin, M. (2004). *Esli mir toropit: stikhi* [If the World Wants You to Go Faster: Verses]. Avtor vvodnykh slov I. Yuzeev. 95 p. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Russian)

20. Vafin, M. (2007). *Chastichka serdtsa: stikhi* [A Piece of Heart: Verses]. 272 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

21. Vafin, M. (2001). *Slova poseyal Pyatistrunnyi saz: stikhi.* [I've Sown Words. A Five-Stringed Saz: Verses]. Pp. 3–110. Ufa, Kniga. (In Russian)

22. Davletshin, K. S. (2002). *Stikhi rodnogo kraya. Individual'nyi stil' i voprosy poehticheskoi obraznosti: uchebnoe posobie* [Poems of the Native Land. An Individual Style and Issues of Poetic Imagery: A Study Guide]. 108 p. Ufa, izd-vo Bashkirskii gos. un-ta. (In Russian)

23. Davletshin, K. (2007). *"Krasotu sotvoril velikii tvoritel' prirody – Chelovek": kartina mira v tvorchestve Farita Gabderakhima* [Beauty Was Created by the Great Maker of Nature – Man": The World Image in the Works of Farit Gabderakhim]. Tulpar. No. 6 (81), pp. 56–61. (In Russian)

24. Davletshin, K. S. (2000). *Dorogie lyudi ryadom...* [Dear People Are Close…]. Stikhotvornoe tvorchestvo Marisa Nazirova: stat'i o tvorchestve poehta / v redaktsii S. Safuanova. Pp. 23–40. Ufa, Obrazovanie. (In Russian)

25. Davletshin, K. (2002). *Poeht "v poiskakh vsyu zhizn'"...* [The Poet Is "Searching All His Life"…]. Tulpar. No. 1 (46), pp. 44–47. (In Russian)

26. Davletshin, K. (1996). *Filosofiya poehta* [The Poet's Philosophy]. Tulpar. No. 1 (10), pp. 34–36. (In Russian)

27. Safuanov, S. (2011). *"Stikhi moi – vy zhe moya krovinushka..."* ["My Verses – You Are My Drops of Blood…"]. Nazmi N. Moya natsional'naya dusha: stat'i, vospominaniya, pis'ma, stikhi, poehma. Avtor idei i sozdatel' R. Miңnullin. Pp. 236–242. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Russian)

28. Safuanov, S. (2006). *Dukhovnye mosty* [Spiritual Bridges]. 376 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

29. Safuanov, S. (2000). *Chuvstvo rodnoi zemli* [The Sense of Your Native Land]. Stikhotvornoe tvorchestvo Marisa Nazirova: stat'i o tvorchestve poehta. V redaktsii S. Safuanova. Pp. 3–10. Ufa, Obrazovanie. (In Russian)

30. Amirov R. (2000). *Kogda est' kryl'ya na plechakh...* [If You Have Wings on Your Shoulders…]. Stikhotvornoe tvorchestvo Marisa Nazirova: stat'i o tvorchestve poehta. V redaktsii S. Safuanova. Pp. 95–102. Ufa, Obrazovanie. (In Russian)

31. Khaibrakhmanov, R. (2011). *Cherez grani. Nazmi N. Moya natsional'naya dusha: stat'i, vospominaniya, pis'ma, stikhi, poehma* [Across the Edges. Nazmi N. My National Soul: Articles, Memoirs, Letters, Verses and a Poem]. Avtor idei i sozdatel' R. Miңnullin. Pp. 4–10. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Russian)

32. Mulekov, M. (1996). *"Vkhozhu v tsentr uragana..."* [Entering the Centre of a Hurricane...]. Tulpar. No. 6 (15), pp. 28–29. (In Russian)

33. Fazletdinov, I. (2010). *Stikhi treeta* [The Poet's Verses]. Ogni Kazani. No. 2, pp. 124–129. (In Russian)

34. Fazletdinov, I. K. (2016). *Sovremennaya tatarskaya poeziya Bashkortastana v kritike* [Modern Tatar Poetry of Bashkortostan through Criticism]. Tatarica. No. 2 (7), pp. 57–72. (In Russian)

35. Gabderakhim, F. (2006). *Esli zakhochesh' vozbudit' narodnuyu dushu...* [If You Want to Excite People's Soul]. Tulpar. No. 1 (70), pp. 54–55. (In Russian)

36. Gatash, R. (1993). *"Ya vizhu odnu yarkuyu vysotu...."* [I See One Bright Summit]. Shakhri Kazan'. 27 fevral'. (In Russian)

37. Mudarisov, M. (2000). *Atnabai (Slova izdatel'stva)* [Atnabay (What the Publishing House Has Got to Say)]. Atnabai. Narodnyi poeht. Pp. 5–9. Ufa, fond "Rukhiyat" Respubliki Bashkortstan. (In Russian)

38. Nazmi, N. (1959). *Rech' poehta* [The Poet's Speech]. Sovet Bashkortostana. 11 gyinvar. (In Russian)

39. Minnullin, R. (2018). *Vstrechaite Atnabaya! Nash Atnabai: stikhi, stat'i, vospominaniya* [Meet Atnabay! Our Atnabay: Verses, Articles, Memoirs]. Avt.-sostavitel'. R. K. Amirov. Pp. 126–130. Ufa, Kniga. (In Russian)

40. Iksanova, I. (2018). *Dusha yarkaya kak rassvet* [The Soul as Bright as Dawn]. Kul'turnaya pyatnitsa. 25 aprel'. (In Russian)

41. *Tatarskii ehntsiklopedicheskii slovar'* (2002) [Tatar Encyclopedic Dictionary]. Glavnyi redaktor M. Kh. Khasanev; otvetstvennyi redaktor G. S. Sabirzyanov. 830 p. Kazan', RT AN institut Tatarskoi ehntsiklopedii. (In Russian)

42. Bikbaev, R. (2009). *V poiskakh ostroumnykh otvetov: doklady predstavlennye na XII s"ezde pisatelei respubliki* [In Search of Witty Answers: Reports Presented at the XII Congress of Writers of the Republic]. Sud'ba zemli, dykhanie vremeni. Pp. 320–364. Ufa, Kniga. (In Russian)

43. Morzakaeva, D. (2012). *Natsional'naya kniga: Ob izdanii natsional'nykh izdanii v bashkirskom izdatel'stve "Kniga" imeni Zainab Biishevoi i o knigakh, izdannykh zdes'* [A National Book: On the Publication of National Editions in the Bashkir Publishing House "Book" Named after Zainab Biisheva and on Books Published Here]. 151 p. Ufa. (In Russian)

44. Murzakaeva, D. (2006). *Duyut Bulgarskie vetry...* [The Bolgar Winds Are Blowing]. Tulpar. No. 2 (71), pp. 56–59. (In Russian)

45. Nazmi, N. (1998). *Po Pushkinski, Tukaevski...* [Like Pushkin and Tukay…]. Tulpar. No. 1 (22), pp. 16–17. (In Russian)

46. Kashfi, L. (2014). *"Krasnyi rassvet" i sovremennaya literatura* ["The Red Dawn" and Modern Literature]. Nauchnyi ruk. F. K. Fatkhetdinov; avt. vvodnykh slov T. N. Galiullin. 300 p. Ufa, Krasnyi rassvet. (In Russian)

47. Latypova, A. V. (2021). *Sovremennaya tatarskaya poehziya Bashkortostana: natsional'naya kartina mira i zhanrovaya paradigma: avtoref. dis. ... kand. filol. nauk* [Modern Tatar poetry of Bashkortostan: The national picture of the world and the genre paradigm: Ph.D. Thesis Abstract]. FGAOU VO "Kazanskii (Privolzhskii) federal'nyi universitet". Kazan', 24 p. (In Russian)

48. Karamysheva, T. (1986). *Spokoinye gorsti* [Calm Handfuls]. Agyidel. No. 3, pp. 72–74. (In Russian)

49. Propp, V. Ya. (1986). *Istoricheskie korni volshebnoi skazki* [The Historical Roots of a Fairy Tale]. Vstup. stat'ya V. I. Ereminoi. 2-e izd. 364 p. Leningrad, izdatel'stvo LGU. (In Russian)

50. *Tatarckie mify: dukhi, pover'ya, sueveriya, zagovory, primety, obryady* (1999) [Tatar Myths: Spirits, Beliefs, Superstitions, Spells, Omens and Rituals].

Vtoraya kniga. V povestvovanii G. Gil'manova. 432 p. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Russian)

51. Minkhazetdinov, M. Kh. (1995). *Est' moshch' v tvorchestve: monografiya, literaturnaya kritika i trudy, otnosyashchiesya k bashkiskoi fol'kloristike* [There Is Power in Creativity: A Monograph, Literary Criticism and Works Related to Bashkian Folklore]. Avt. vvodnykh slov T. A. Kil'mukhammetov i A. M. Suleimanov. 256 p. Ufa, Kniga. (In Russian)

52. Tursunov, E. D. (1973). *Genezis kazakhskoi bytovoi skazki: v aspekte v svyazi s pervobytnym fol'klorom* [Genesis of the Kazakh Folk Fairy Tale: In the Aspect of the Primitive Folklore]. 216 p. Alma-Ata, Nauka.

53. Gizzatullina, G. (1998). *"Stikhi – dlya nego..."* [These Verses Are for Him…]. Tulpar. No. 5 (26), pp. 54. (In Russian)

54. Sagitova, G. (2005). *Ot momentov – k vechnosti* [From Moments to Eternity]. Tulpar. No. 1 (64), pp. 30–31. (In Russian)

55. Atnabai, A. (1995). *Stoya v seredine zemli, ozirayus' s udivleniem* [Standing in the Cetre of the Earth, I'm Looking aroud Surprised]. Krasnyi rassvet. 15 avgust. (In Russian)

56. Sagidullina, L. (2004). *Minor Munir: vzglyad na tvorchestvo poehta* [Minor Munir: A Glance at the Poet's Work]. Tulpar. No. 4 (61), pp. 28–30. (In Russian)

# БАШКОРТСТАНДАГЫ ТАТАР ПОЭЗИЯСЕНДӘ ШАГЫЙРЬЛӘР БУЫНЫ МӘСЬӘЛӘСЕ

**Илдус Камил улы Фазлетдинов,**
Уфа Фән һәм технологияләр университеты,
Россия, 450076, Уфа ш., Зәки Вәлиди ур., 32 нче йорт,
fazlutdinov75@mail.ru.

Фәнни мәкаләдә 1950 – 2020 елларда Башкортстан җирлегендәге татар шигъриятендә буыннар мәсьәләсе тикшерелә. Хезмәттә фәнни-хронологик һәм диахроник аспектлар яссылыгында Башкортстандагы татар шигъриятенең үсешенә күзәтү ясала; төбәктәге татар әдипләренең икегә бүленеп, бер өлешенең – татар, икенченең башкорт сүз сәнгатьләренә хезмәт итүенең тарихи-мәдәни сәбәпләре, сәяси вәзгыятьнең шигърияткә һәм шагыйрьләрнең индивидуаль стиленә йогынтысы анализлана. Автор, күпсанлы гыйльми-тәнкыйди чыганакларны файдаланып, әдәбият гыйлемендә кабул ителгән фәнни классификация принциплары ярдәмендә, Башкортстандагы татар шагыйрьләренең чынбарлыкны сәнгатьчә гәүдәләндерү үзенчәлекләрен ачыклый. Язмада шагыйрь аңындагы дөнья картинасының индивидуаль стильне барлыкка китерүче төп категория булуы ассызыклана, һәм, шуннан чыгып, Уфа төбәгендәге татар поэзиясенә хас гомум һәм һәр каләм остасының үзгә сыйфатларын ачыклау омтылышы ясала. Поэтик әсәрләрне иҗат юнәлеше һәм ысулы, эчтәлек һәм форма, үзәк мотивлар ноктасыннан анализлап, автор төбәктәге татар шигърияте вәкилләрен дүрт буынга аера, аларның һәркайсы өчен үзенчәлекле һәм Башкортстан татар поэзиясе өчен уртак сыйфатларны билгели. Мәкаләдә төбәк татар поэзиясенең поэтик сыйфатлары, идея-эстетик эчтәлеге ягыннан татар шигъриятенең меңьеллык традицияләренә нигезләнүе ассызыклана.

**Төп төшенчәләр:** шигърият, индивидуаль стиль, буын, әдәби тәнкыйть, Башкортстан, иҗат юнәлеше, иҗат ысулы, поэтик образ

## Кереш

Башкортстандагы татар шигърияте, аның үзенчәлекләре, каләм әһелләренең шәхсиятле стиль билгеләре турында фикер йөрткәндә, буыннар мәсьәләсе мөһим аспект булып тора. Дәһшәтле сугыш елларында, яисә Сталин дәверендә дөньяга килеп, шул чорда хакимлек иткән идеологик карашлар һәм мәдәни шартларда тәрбияләнгән өлкән буын вәкилләре белән «үзгәртеп кору» яки 1990 еллардагы милли үзаң күтәрелеше чорында шәхес буларак формалашкан каләм әһелләре арасында дөньяны күзаллауда, аны поэтик гәүдәләндерү алымнарында аерма шактый зур.

Башкортстандагы татар әдипләрен буыннарга нисбәтле төркемләү мәсьәләсе тикшеренүчеләрне дә, каләм әһелләрен дә күптәннән кызыксындырып килә. Мәсәлән, 2000 еллар башында шагыйрь Мөнир Вафин тәнкыйтьче Сәгыйдулла Хафизов белән барган бәхәстә, Башкортстанда татар телендә иҗат итеп, үзләрен татар шагыйрьләре дип исәпләүчеләрне

дүрт буынга аера: «Әйтик, өлкән буыннардан бу сафка Фәрит Габдерәхим, Рәшит Гатауллин һәм Рим Идиятуллинны кертер идем, – ди ул. – Урта буында Салават Рәхмәтулла, Рәдиф Тимершин, Марис Нәзировлар. Яшьрәк буынга Мөнир Вафинны, Марат Кәбировны һәм Рамил Чурагуловны кертәм, һәм иң яшь буын дип Илдус Фазлетдинов, Илфак Фаризов, Илдар Фазлетдинов, Рәзиф Зөбәеровларны атарга була» [1, 23 б.]. Автор хатын-кыз шагыйрәләрне аерым катлам буларак карый һәм Дилә Булгакова, Халисә Мөдәррисова, Нәҗибә Әминева, Рафига Усманова, Кәүсәрия Шәфыйкова, Нәфисә Хабибдиярова, Гүзәлия Тимершина, Әлфия Булат кебек каләм әһелләрен саный [1, 23 б.]. Бу бүленеш шагыйрьләрнең яшенә нигезләнә.

Галимә Л. Ваһапова исә үзәккә шагыйрьләрнең яшен түгел, ә иҗади биографиясен, шигърияткә килү вакытын, осталык дәрәҗәсен куя. «Дәвамчанлык принцибыннан чыгып, Башкортстандагы хәзерге көн язучыларын шартлы өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин, – дип яза ул. – Инде киңәшче ролен үтәүче, әйдәп баручы өлкән буын иҗатчылары – Салават Рәхмәтулла, Эдуард Әгъзами, Рим Идиятуллин, Халисә Мөдәррисова, Рәис Риян, Азат Магазов, Фәрит Габдерәхим, Дилә Булгакова, Вил Казыйханов, Мөхәммәт Закиров, Сәгыйть Хафизов һәм башкалар.

Иҗат өлкәсендә үз өслүбен тапкан язучыларыбыз Рәдиф Тимершин, Мөнир Вафин, Лилия Сәгыйдуллина, Илдус Фазлетдиновлар каләме дә язудан туктаганы юк. Тәҗрибәле иҗатчылар Дилбәр Булатова, Фәния Габидуллина, Зәйфә Салихова, Рафаил Хафизовлар Башкортстандагы татар шигъриятен һәм прозасын үстерүгә зур өлеш кертүчеләр исемлегендә.

Әдәбият дигән зур дөньяда үз юлын ярып барган өметле яшь каләм тибрәтүчеләр дә аз түгел. Йомабикә Солтанова, Фәрит Фәткуллин, Айдар Зәкиев, Фәнзия Максютова, Фәүзия Гайзаман, Венер Фәттахов, Халисә Мөхәммәдиева, Индира Муллаянова, Эльмира Ибраһимова, Аида Хәйретдинова, Миләүшә Гыйльманова, Руслан Сөләйманов, Земфира Муллагалиева һәм башкалар, инде җыентыкларын бастырып, үз укучыларын тапты» [2, 103 б.].

Күренә ки, «яшь каләм тибрәтүчеләр» төркеме яшьләре 50 елдан артып киткән шагыйрьләр һәм язучыларны берләштерә. Мәкалә авторы аларны үз стилен, үз тавышын эзләүчеләр дип бәяли.

Кызганычка каршы, әлеге мәкалә басылганнан соң үткән ун ел эчендә С. Рәхмәтулла, Э. Әгъзами, Р. Идиятуллин, Р. Риян, А. Магазов, В. Казыйханов, М. Закиров, Р. Тимершин кебек өлкән әдипләр бакыйлыкка күчте. Шул ук вакытта төбәк татар шигърияте Фатыйх Сәйфран, Ләйсән Якупова, Рәсим Шәфи-Рәхмәт, Эльверт Хаматшин, Альбина Хәлиуллина, Нурлан Ганиев, Айдар Маннанов, Гөлфизә Кәлимуллина исемнәре белән баеды. Алар бер-берсеннән яшьләре, иҗтимагый карашлары, әдәби өслүбләре белән аерыла. Димәк, Башкортстандагы татар шигъриятендә буыннарны билгеләүдә «биологик яшь» принцибы үзәктә тора алмый. Бүленешкә иҗтимагый-сәяси, идеологик факторлар, гомум әдәбиятның үсеш тенденцияләре, әдипләр иҗатында дөнья картинасының үсеш-үзгәреше дә йогынты ясый. Бу аспект хезмәтнең актуальлеген һәм фәнни яңалыгын билгели.

**Тикшеренү материаллары һәм методлары**

Гыйльми мәкаләдә фәнни-тикшеренү материалы сыйфатында XX йөзнең икенче яртысыннан алып бүгенгә кадәр Башкортстан җирендә яшәп, татарча иҗат иткән шагыйрьләр – Н. Нәҗми [3], Ә. Атнабаев ([4], [5]) Ф. Габдерәхим [6], Р. Идиятуллин [7], Рәшит Гатауллин [8], Х. Мөдәррисова ([9], [10], [11]), М. Нәзиров [12], М. Закиров ([13], [14]), С. Рәхмәтулла ([15], [16]), Н. Әминева [17], Л. Сәгыйдуллина [18], М. Вафинның ([19], [20], [21]) шигъри җыентыклары файдаланылды. Тикшеренүнең методологик нигезен К. Дәүләтшин ([22], [23], [24], [25], [26]), С. Сафуанов ([27], [28], [29]), Р. Әмиров [30], Л. Ваһапова [2], Р. Хәйбрахманов [31], М. Мөлеков [32], И. Фазлетдинов ([33], [34]) һ.б. галимнәрнең хезмәтләре тәшкил итте. Үзәккә куелган мәсьәләне ачыклауда автор, нигездә, тарихи, тарихи-чагыштырма, тарихи-типологик һәм герменевтика тикшеренү методларына таянды.

**Фикер алышу**

Башкортстандагы татар шигърияте турында сүз алып барганда, бер хакыйкатьне истә тотарга кирәк: 1934 – 1991 елларда әдәбият тулаем партия диктаты астында булып, «бер республика – бер әдәбият» принцибы эзлекле рәвештә тормышка ашырылды. Татар гаиләсендә туып-үсеп, татарча укыган һәм үз милли мохитебездә тәрбияләнгән каләм ияләре иҗатка керешкәч, я башкортча язып, күрше милләт язучысы булып китәргә, яисә татар әдибе

буларак үз-үзен раслар өчен, Казанга күченеп китәргә мәҗбүр булды. Шулай итеп, шагыйрь Фәрит Габдерәхим тарафыннан «башкорт һәм татар әдәбиятлары – Башкортстандагы татар әдәбиятының ике канаты» [35, 54 б.] дип билгеләнгән парадоксаль күренеш барлыкка килде.

Ф. Габдерәхимгә таянып фикер йөрткәндә, Нажар Нәҗми һәм Әнгам Атнабаев Башкортстандагы сугыштан соңгы беренче буын татар шагыйрьләре буларак карала. Алар икесе дә башкорт әдипләре булып исәпләнсәләр дә, туган телләре татар теле булды. Иҗатларында татар моңы, меңьеллык поэтик традицияләренә таяну хосусиятләре, татар теленең киләчәк язмышы мотивы үзәктә тора. Билгеле булганча, Н. Нәҗми үзенең 1984 елда Казан дәүләт университеты профессоры Миркасыйм Госмановка багышлап иҗат иткән «Париж өстендә» шигырендә болай дип яза:

*Без – татар һәм башкорт – кан кардәшләр,*
*Миндә исә тибә ике кан:*
*Үзем башкорт, әмма татар теле –*
*Анам теле миңа тумыштан* [3, 261–262 б.].

Ә. Атнабаев исә үзен татар халкының бер өлеше дип саный. «Мин – чи татар башкорт илендә» дип, гомер буена татар телендә иҗат итә.

Р. Хәйбрахманов билгеләгәнчә, 1950–1980 елларда Н. Нәҗми «лирикасында публицистик аһәң белән беррәттән каһарманның эмоциональ палитрасында пессимистик хис-тойгыларның (тормыштан канәгатьсезлек, гомернең үтүе, иҗатның максатсызлыгы һәм кирәксезлеге, шагыйрь һәм аның милләтенең кадерсезлеге мотивлары. – *Р.Х.*) көчәюе күзәтелә. Бу күренешнең сәбәпләрен шагыйрь яшәгән чордан, торгынлык һәм татар, башкорт кебек кече милләтләрнең үсешен тоткарлаган Брежнев режимы сәясәтеннән эзләргә кирәктер» [31, 6 б.].

Н. Нәҗминең татар халкына, аның фаҗигале язмышына багышлап язган шигырьләр шәлкемен шартлы рәвештә «каршылык лирикасы» үрнәкләре дип бәяләргә мөмкин. Күренекле әдәбият галиме С. Сафуанов шагыйрьнең милли тел өчен көрәшкә ташлануын билгели [27, 239 б.]. Аның иң көчле чагылышы шагыйрьнең 1966 елда рус шагыйре Я. Смеляковка җавап төсендә язылган «Татар теле» шигырендә күзәтелә.

*Ассалар да, киссәләр дә,*
*Үлмәдең син, калдың тере.*
*Чукындырган чагында да*
*Чукынмадың, татар теле* [3, 244–245 б.]

Бу шигырьне Башкортстанның, Татарстанның бер матбагасы да басмый, ул, еллар үткәч, Мәскәүдә нәшер ителгән «Учительская газета»да русча тәрҗемәдә дөнья күрә. «Н. Нәҗми өчен Ватан, ана дигән изге төшенчәләр өченче бер газиз күренеш белән дә аерылгысыз. Бу туган тел. *«Ватан, – димен, – анам туган җир, Ватан, – димен, – атам туган җир... Ватан, – димен, – атам һәм анам сөйләшкән тел – туган телем ул»*, – дип язды шагыйрь» [27, 239 б.].

Н. Нәҗми үзенең атаклы «Татар акылы» (1990) шигырендә әйтемгә әверелгән бер милли җитешсезлекнең фаҗигале нәтиҗәләренә, тарихтагы чагылышына, укучының игътибарын юнәлтеп, риторик сорау ташлый:

| | |
|---|---|
| *Ни булды? Үз юлыңа син*<br>*Үзең салдыңмы йозак?*<br>*Башыңны ашады мәллә*<br>*Үзара булган низаг?* | *Бүген дә Кояш чыкты, дип*<br>*Уйланып торам иртән.*<br>*Татар акылы төштән соң...*<br>*Кайчан төш җитәр икән?* [3, 269 б.] |

«Татар генераллары» (1994) шигырендә Мәскәүдә оештырылган татар генераллары һәм адмираллары җыелышына нисбәтле, хәрбиләрдән бигрәк, милли элитага, шул исәптән, шагыйрьнең үзенә сатирик мөнәсәбәт белдерелә. «Татар хатын-кызлары» (1991) шигырендә автор, күнегелгән әдәби кануннар буенча, гүзәл затларның «уңган, дәртле, сылу, эшчән» кебек уңай сыйфатларын саный да, башка милләт кешесенә кияүгә чыгып, тел, дин алыштыруда, шул халыкның буын алмашын тәэмин итүдә гаепли һәм аны милләт өчен фаҗига югарылыгына күтәрә.

| | |
|---|---|
| *...Язмышмы ул, фаҗигаме*<br>*Сез күргәннәр, кичергәннәр?*<br>*Сез түгелме*<br>*Урысларга – урыс,*<br>*Үзбәкләргә – үзбәк,*<br>*Казакъларга – казакъ,* | *Кыргызларга кыргыз*<br>*(Тик бер мисал – Чыңгыз)*<br>*Тудырганнар, үстергәннәр,*<br>*Татар хатын-кызлары?*<br>*Язмышмы бу, фаҗигаме?* [4, 269 б.] |

Шулай итеп, «тарих борылышларында сакланып калу – милләтне борчыган бу гаять мөһим проблеманы хәл итү юлын Нажар Нәҗми, Г. Исхакый һәм Г. Тукай кебек үк, туган телгә һәм милли язмышка хөрмәт тәрбияләүдә күрә» [31, 10 б.]. Күренекле шагыйрь рухи дөньясының асыл хасияте Р. Гаташ тарафыннан бик оста тотып алына: «Ул

– барыннан да бигрәк, татар халкының, татар теленең батыр яклаучысы, тоталитар система төрле яктан кысып торган елларда, курыкмыйча, аңа ярдәмгә килгән ир-узаман. <…> Сабыры тулып, татар җанын, канын тыеп килә белгән кем ул? Наҗар ага. <…> Үзен “башкорт шагыйре”, милләте белән дә “башкорт” санап, әмма туган теле татар теле, Тукай теле икәнлеген <…> кычкырып әйтүче, горурланучы да ул булды» [36].

Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабаев төбәк татар шигъриятенең нигез ташын салган әдипләрнең берсе булып тора. Иҗатында татарлык хисе, милли гамь төп лейтмотив булса да, Ә. Атнабаев шигырьләре «халыкларны талаштыруга түгел, туганлаштыруга корылган иде» [37, 8 б.]. Аның 1956 – 1985 еллар шигъриятендәге татарлык хисе Н. Нәҗми иҗатындагы публицистик аһәң, милли изелүгә «каршылык лирикасы» рәвешендә түгел, ә, беренче чиратта, татар халкының милли фольклорында, меңьеллык шигъриятендә төп урынны тоткан традицион образларга яңа, заманча эчтәлек салу аша гәүдәләнеш тапты. «Капка төбендә» (1956), «Яшь каен» (1957), «Туфрак» (1957), «Утыз яшь» (1958), «Кара икмәк» (1960), «Миннән башка» (1960), «Ак каеннар кая булганнар?» (1961), «Яшь егетләр чалгы яныйлар» (1961), «Сары сандугач, кара карлыгач» (1964), «Әкияттәге кебек» (1964) һ.б. башлангыч чор иҗатына караган шигырьләреннән үк татар шигъриятенең бөтен тарихы аша кызыл җеп булып сузылып килгән *ак каен, туган җир, сары сандугач, гармун* кебек традицион образлар, халык җырларының поэтикасы, әкиятләргә хас башлам-бетемнәр, образлар системасы яңа яңгыраш ала. Н. Нәҗми әйткәнчә, аның әсәрләрендә «... шагыйрьнең “мин” дигән лирик герое, якын дустымы, улымы, кызымы, егетеме, гармунчымы, солдатмы – нинди дә булса шәхес хәрәкәт итә. Менә шулай булу шигырьне җанландыра, укучыны я уйландыра, я елмайта, бер сүз белән әйткәндә, тойгы уята» [38]. Бу хосусиятләр киләчәктә Ә. Атнабаев шигъриятенең йөзен билгеләгән асыл сыйфатлар рәвешендә калкып чыга.

1980 еллар башында Ә. Атнабаев иҗатына «татар» концепты конкрет килеп кереп, шигырьләрендә публицистик аһәң көчәя, шагыйрь үз язмышын халык язмышы белән бербөтен итеп карый башлый. Әлеге тенденция шагыйрьнең 1982 елда язылган «Газаплы сорау» шигырендә ачык чагыла.

| | |
|---|---|
| *Күп гасырлы бөек*<br>*тарихында*<br>*Күп сыналды татар*<br>*баласы...*<br>*Сугыш елларында*<br>*әсирлектә –*<br>*Төрмәләрдә*<br>*фашист палачы*<br>*Башын кискәндә дә*<br>*Үзебезчә*<br>*Җырлап үлде татар*<br>*уллары;* | *Җырлап үлгән татар*<br>*улларының*<br>*Бүген яшәп яткан*<br>*уллары,*<br>*Телегезне кемнәр*<br>*алыштырды,*<br>*Җырыгызны кемнәр*<br>*урлады?*<br>*Йөрәгемне шундый*<br>*сорау телә,*<br>*Тынгы бирми шуның*<br>*газабы.* [4, 96 б.] |

Шигырьдә Ә. Атнабаевның 1960–1970 еллар шигъриятендәге лирик җылылыкны, нечкә юмор хисен публицистик рух, туган телнең, мәдәниятнең югала баруына борчылу, ачыну хисе алыштыра. Туган җире – Башкортстанда шигырьләрен татар телендә чыгара алмау, башкорт зыялылары тарафыннан үгисетелеп яшәү шагыйрь күңелендә ризасызлык хисен тагын да көчәйтә. Татар – башкорт мөнәсәбәтләре мәсьәләсен бар тулылыгы, дөреслеге белән матбугатта әдәбиятта күтәреп чыккан беренче шагыйрь дә Әнгам Атнабаев булды:

| | |
|---|---|
| *«Ник татарса*<br>*һөйләшәһең,*<br>*Башкортса һөйләш,*<br>*имеш,*<br>*Был һөйләшең менән*<br>*һиңә*<br>*Казанга китеү*<br>*тейеш!»*<br>*Нишләп Казанга*<br>*китим ди?*<br>*Шушында атым-*<br>*затым –*<br>*Минем сөйләшне*<br>*аңлаучы*<br>*Миллионнан артык*<br>*халкым.* | *Нишләп Казанга*<br>*китим ди?*<br>*Шушында минем*<br>*Уфам,*<br>*Казанда яшәп Уфаны*<br>*Сагына иде Туфан...*<br>*Моннан ары «һин*<br>*татар» дип,*<br>*Җаныма тимә, давай.*<br>*Җанга тиеп, җан*<br>*ачуын*<br>*Чыгара күрмә, малай!*<br>[5, 362 б.] («Милли<br>“дус”ка», 1984*)* |

Шагыйрь «Мәсьәлә» шигырендә ике милләт зыялылары арасында барган бәхәс-каршылыкларның ясалма булуын, татар һәм башкорт халыклары алдында уртак бәла – туган телне югалту, катнаш никахлар күбәеп китеп, милләтләрнең юкка чыгу куркынычы алдында торуы хакында чаң суга [4, 119 б.].

1993 елда Татарстанның халык шагыйре Р. Миңнуллин бик хаклы рәвештә болай дип әйтә: «Атнабай үзенең шигъри мәктәбен тудырган шагыйрь» [39, 127 б.]. Татар шагыйрьләренең аннан соңгы буын вәкилләре Р. Идиятуллин, Х. Мөдәрисова, С. Рәхмәтулла, М. Нәзиров, М. Кәбировлар шагыйрь «канаты» астында тәрбия-

ләнеп, «Атнабай мәктәбе» әдәби традицияләрендә, поэтик алымнарында формалаштылар.

Нажар Нәҗми һәм Әнгам Атнабаевның шәкертләре – татар телендә иҗат итеп, татар шагыйре буларак танылган Фәрит Габдерәхим, Рим Идиятуллин, Рәшит Гатауллин, Халисә Мөдәррисовалар Башкортстандагы татар шигъриятенең икенче буынын барлыкка китерә. Фәрит Габдерәхим, 1994 елда республикада татар телле язучылар берлеге оештырылгач, рәсми рәвештә үз теләге белән Башкортстан Язучылар союзыннан чыгуын белдерде, калган өчесе Башкортстан язучыларының һөнәри берлегендә әгъзалыкка дәгъва кылмыйча, 1993 – 1994 елларда чит төбәкләрдә яшәүчеләр арасында беренчеләрдән буларак, Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителделәр.

Әдәбият галиме С. Сафуанов Ф. Габдерәхим иҗатын ике чорга аера: а) 1980 еллар ахырына кадәрге чор; б) 1990–2000 еллар шигърияте [28, 341–342 б.]. Баштагы утыз еллык иҗат гомерендә шагыйрьгә үзенең шигырьләрен һәм поэмаларын Уфада башкорт телендә чыгарырга туры килә. Башкортстан китап нәшриятында «Йөрәк уты» (1971), «Җирдәге йолдызлар» (1975), «Анкетага кермәгән юллар» (1978), «Алтын туй» (1982), «Күңел күзе» (1985), «Гашыйклар, сезгә генә» (1988) дип аталган китаплары бер-бер артлы нәшер ителә. Шул ук вакытта шигырьләре «Казан утлары»да туган телендә һәрдаим дөнья күрә.

Туксанынчы еллардан башлап, Башкортстан китап нәшриятында татар телендә китаплар чыгаруга юл ачылгач, Ф. Габдерәхим иҗатының икенче чоры башлана. Бүгенге көнгә кадәр дәүләт нәшриятында аның «Кичер мине!..» (1996), «Синең белән мин» (2002), «Гөлләр кебек!» (2015), “Сине яратам” (2023) дип аталган күләмле шигъри җыентыклары нәшер ителә. Болардан тыш шагыйрьнең шәхси нәшриятларда үзнәшер ысулы белән чыгарылган берничә китабы да бар.

Ф. Габдерәхим шигърияте галимнәр һәм тәнкыйтьчеләрдә зур кызыксыну уята. Тәнкыйтьче С. Сафуанов Ф. Габдерәхим лирик героеның шагыйрь шәхесеннән аерылмавын ассызыклый [28, 341 б.]. Әдәбият галиме К. Дәүләтшин шагыйрьнең шартлы-романтик фикерләү сыйфатын башкалардан аерып күрсәтә. [23, 57 б.]. Әлеге караш, тәнкыйтьче-галим М. Мөлеков тарафыннан да хупланып, шагыйрь иҗатының асылда логик образларга корылуы әйтелә [32, 29 б.]. К. Дәүләтшин шагыйрьнең индивидуаль стиле турындагы карашларын дәвам итеп, аның шигъриятендә фикер һәм хиснең бердәмлеген билгели: «Фәрит Габдерәхим иҗатында еш кына фикер образдан туа, ягъни җанлы образ бай фикергә нигез буларак гәүдәләнә. Бу исә – поэтик талант билгесе» [23, 57 б.]. Шуңа нигезләнеп, шагыйрьнең образлы фикерләү тибы сәнгатьчел-аналитик дип нәтиҗә ясала [23, 57 б.]. Дәлил итеп «Сагындыра» (1968) шигыреннән өзек китерелә: «*Биеклектән тау да масаймый бит, / И беркатлы гамьсез сабыйлык! / Инде күптән бәлигъ булып җиттем, / Ярсуларга хуҗа сабырлык.* ...Күренә ки, – ди К. Дәүләтшин, – строфадагы беренче тезмәдә символик мәгънәле афористик фикер, икенче тезмәдә гомер фасылына тойгылы бәя, соңгы тезмәләрдә лирик “мин”нең үзенә кагылышлы аналитик мөнәсәбәт, кыскасы, хис бөркелгән аналитик шигырьгә хас сыйфатлар ачык чагылган» [23, 58 б.].

С. Сафуанов билгеләгән аклык-сафлык үрнәге шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында Туган җир һәм анда яшәүче кешеләр гәүдәләнешендә чагыла. «Ятсынмыйлар күркәм тупылларым...» (1960), «Җир бәйрәме» (1965), «Юл белмим диеп торма син» (1975), «Кандракүлдә» (1970), «Авылым – Арсланым» (1986) кебек шигырьләрендә Фәрит Габдерәхим аларны романтик күтәренкелек белән тасвирлый. Шунысы мөһим: иҗат тәҗрибәсе зураю белән, шагыйрь поэзиясендә туган җир образының гәүдәләнеше үзгәрә. Аның шигъриятендә фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле Туган җир – газиз Әнкәй параллеле барлыкка килә:

| | |
|---|---|
| *Туган җирнең бөтен бизәкләрен<br>Чагылдыра минем Әнкәем!<br>Әнкәй сыны – туган җирем сыны...* [6, 28–29 б.] («Әнкәй сыны», 1985) | *Кичерәдер мондый чакта<br>Тик әнкәйләр, туган яклар.* [6, 24–25 б.] («Әниләр һәм туган яклар», 1970). |

Шагыйрь иҗатында ул фикри-мәгънәви яктан тагын да тирәнәйтелеп, *Табигать – газиз Ана* образына үстерелә:

*Бәлки давыл тынар җанда,*
*Сызылып таң ата инде.*
*Әниләрне,*
*Башка исем тап дисәләр,*
*«Кояш!» дип атар идем.* [6, 30–31 б.] («Кояш», 1972)

Шулай итеп, *хәтер, ана, туган як табигате* образлары Ф. Габдерәхим поэзиясендәге дөнья моделен шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирә. Дөрес, ул да замана баласы булып кала, чор идеологиясен «җимереп чыкмый». Әмма иҗатының икенче чорында миллилек, татар халкының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында гамьнәр аның шигъриятенең төп мәсләгенә әверелә.

Башкортстандагы татар поэзиясенең күренекле вәкиле Рим Идиятуллин бик соңлап танылa. Аның «Хәерле иртә» дигән беренче җыентыгы 1983 елда Уфада башкорт телендә дөнья күрсә, ә икенче «Хәерле көн» китабы, 14 ел узгач кына, 1997 елда Башкортстан китап нәшриятында татар телендә басылып чыга. 2007 елда Р. Миңнуллин аның шигъри әсәрләрен туплап, «Хәерле кич!» исеме белән Казанда Татарстан китап нәшриятында бастырып чыгара. 2017 елда исә шунда ук шагыйрьнең «Хәерле төн!» дип аталган шигъри тупланмасы нәшер ителә.

Шигырьләре вакытлы матбугатта, күмәк җыентыкларда пәйда булу белән үк, Р. Идиятуллин үзен кабатланмас каләм остасы буларак раслый. Н. Нәҗми Р. Идиятуллин шигъриятенең байлыгын, шагыйрьнең тирән фикерләү сәләтен, шигърияттә иң төп аргумент саналган йөрәк януы белән тирән һәм каршылыклы хисләрен укучыга җиткерү осталыгын билгели [3, 71 б.]. К. Дәүләтшин шагыйрь әсәрләренең укучыга эмоциональ тәэсир итү көчен сүз ярдәмендә картина тудыру осталыгы белән сәбәпле бәйләнештә карый һәм аны буяулар белән эш итүче рәссамга тиңли: «Рим Идиятуллинның шигъри рәсем-картина иҗат итү осталыгы, гаять үзенчәлекле рәссам сәләтенә ия булуы сокландыра» [22, 35 б.]. Ул үз фикеренә дәлил итеп шагыйрьнең «Сукыр» дигән әсәрен китерә:

| | |
|---|---|
| *Җир тәненә*<br>*Суга да ул*<br>*Таягы белән,* | *«Авырттымы?» дигән кебек*<br>*Сыйпап уза*<br>*Табаны белән* [7, 23 б.]. |

Галимнәр билгеләгәнчә, Р. Идиятуллин стиленә гадәти, гади генә саналган хәл-күренешнең рәсемен тасвирлау аша яшәешнең тирән драматизмын ачып салу сыйфаты хас. Бу үзенчәлек аның тәүге тәҗрибәләрендә үк сиземләнә: *Сугыш бетте; / Ә малайлар һаман, / Матчадагы талчыбыкка карап, / «Усал» әтиләрен көтте* [7, 21 б.]. Сүз ярдәмендә тудырылган сурәттә әтиләре сугыш кырында мәңгелеккә ятып калган малайларның тирән фаҗигасе тасвирлана.

Алга таба Р. Идиятуллин шигъри дөньясы халык авыз иҗаты традицияләре, традицион фольклор образлары аша заман чынбарлыгын, чор проблемаларын ачу сыйфаты белән байый. Ул «Толлар урамында» циклындагы «Гөлҗамалның каладагы бер иртәсе» шигырендә ачык гәүдәләнә: *«Китә-әү...» Тукта, көйләр көйләгәнче, / Ипи-тозын чемчим иң башта; / Казлар, бәлкем, очып кайткандыр да, / Кызым калды ерак Донбасста...* [7, 114 б.].

Заманында ир-егетләр туган авылларын ташлап, «бәхет кошы» артыннан чит якларга чыгып киткәннәр, һәм, беркадәр байлык, акча туплап, туган якларына, сөйгән ярлары, газиз ата-аналары янына кайтканнар. Гаилә корып, балалар үстереп, нәсел-ыруны дәвам иткәннәр. Р. Фәхретдинов, Г. Исхакый тарафыннан «милләт анасы» буларак бәяләнгән хатын-кызлар бүген «Донбасска китүче каз» хәлендә: алар күңел җылыларын да, сөю-назларын да күбрәк чит милләт вәкилләренә бүләк итәләр, аларга балалар үстерәләр. «Донбасска очкан» кызлар «...беркайчан да үз тамырларына, үз теленә, үз халкына әйләнеп кайтмаячак... Казлар киткән җирләреннән очып әйләнеп кайтса да... Кызлары белән бергә милләт тә Мәңгелек чоңгылында югала... Шушы фаҗигане күңелләрне тетрәндерерлек итеп нибары дүрт юлга сыйдырган шагыйрь!» [33, 126 б.]. Халык авыз иҗаты традицияләрен иҗади үстереп, кыз һәм каз параллеле аша автор бүгенге көннең милли фаҗигасенә үз мөнәсәбәтен белдерә, аңа борчыла.

Р. Идиятуллин белән бер дәвердә иҗат итә башласа да, хаксыз рәвештә игътибарсыз калган Рәшит Гатауллин икенче буынның бер вәкиле булып тора. Аның тәүге шигырьләре 1968 елда «Беренче карлыгачлар»да Зөлфәт, М. Әгъләмовлар әсәрләре белән бергә дөнья күрсә дә, «Сагышлы моңнар» дип аталган бердәнбер җыентыгы, шагыйрьнең үлеменнән соң, бертуганнары Рәфит һәм Рәдиф Гатауллиннар тырышлыгы һәм Р. Миңнуллинның кереш сүзе белән Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты.

Р. Гатауллинның беренче шигырьләре яшьлек романтикасы, берникадәр самимилеге, дөньяны үзенчәлекле сурәтләү осталыгы белән характерлана. Гомумән, шагыйрь әсәрләре «темалары белән дә, стильләре, формалары белән дә бер-берсен кабатламый» [8, 8 б.] Җәй

көне» шигырендә ул җәй фасылын, һич көтелмәгәнчә, әнисе белән чагыштыра:

| | |
|---|---|
| *Күзләре күз түгел,*<br>*Язлары яз түгел.*<br>*Җәй генә охшаган.*<br>*Яшелдән ясанган,* | *Эсседән сусаган, –*<br>*Әле генә эштән*<br>*кайткан*<br>*Әнигә охшаган* [8, 15<br>б.]. |

Р. Миңнуллин ассызыклаган индивидуальлек, шагыйрь рухи мирасын вакыт агышында тикшергәндә, аеруча ачык күренә: 1960 еллар шигъриятендә романтик күтәренкелек, мәхәббәт хисләре өстенлек итсә, 1970 елларда алар фани дөнья, яшәеш мәсьәләләре белән бергә үрелеп бирелә башлый; милләт, ил язмышы мотивлары 1980 еллар иҗатының үзәгендә ята. Ә туган як – Башкортстан темасы Р. Гатауллин иҗатының лейтмотивы булып тора. Шагыйрь күңелендә Туган җиргә мәхәббәт хисе белән Казанга тартылу хисенең көрәшен К. Дәүләтшин бик оста тотып алган: «Башкортстанда яшәүче татарлар арасыннан әдәби омтылышы белән мавыккан кешегә, гадәттә, катлаулы дилемманы чишәргә туры килә, чөнки ул ике юл чатында торып кала. Әгәр аңарда “туган җир тойгысы” көчлерәк икән, ул илендә иҗат итә, ләкин аны Казан тарта – Тукай рухы чакыра. Шуңа да:

| | |
|---|---|
| *...Шул Марстан, шул*<br>*Сәеттән үтеп,*<br>*Хәзер инде кая*<br>*барасың?*<br>*Уфа – Казан... Гомер*<br>*буе сызлар*<br>*Йөрәктәге олы яра*<br>*син,*<br>*Уфаларда ятим*<br>*итсәләр дә,*<br>*Казанда соң мине кем*<br>*көтә?* | *Тукай рухы, Сибгат,*<br>*Туфан рухы*<br>*Гомер буе шулар*<br>*җилкетә...*<br>Әйе:<br>*Казаннарга барсам,*<br>*Казан мине*<br>*Үги итмәс иде, чит*<br>*итмәс.*<br>Ләкин:<br>*Чәрмәсәнем,*<br>*Кармасаным гына*<br>*Ничек ташар икән*<br>*мин киткәч,* |

ди Кушнаренко районы Марс авылы егете Рәшит Гатауллин» [22, 10–11 б.].

Остазы Н. Нәҗми иҗатындагы кебек үк, шагыйрь өчен дә туган җир, Ватан төшенчәсе туган тел төшенчәсенә тәңгәл килә, алар янәшә куела. Р. Гатауллин поэзиясендәге «үз җиреңнең үги баласы» итеп тоюдан килеп чыккан рухи дисгармония турыдан-туры туган тел язмышы белән бәйле: *...Бүлешергә мөмкин җирне, суны, / Илне мөмкин тартып алырга. / Йортсыз-җирсез торырга да була, / Тик язмасын телсез калырга* [8, 200 б.] («И туган тел»).

Р. Гатауллин 1960 – 1980 еллар иҗатында катлаулы эволюция кичерә: башлангыч чорда язылган шигырьләрендәге романтизм иҗат юнәлешеннән ул кырыс реализм позициясенә күчә. Бу күчеш-метаморфозалар шигъри әсәрләренең тематикасында, идея-эстетик эчтәлегендә, образлар системасында чагыла. Фикри һәм сәнгати күчештә чор иҗтимагый-сәяси вәзгыяте зур роль уйный.

Иҗат юлын 1970 елларда Башкортстанда башлап, төбәктәге яңа чор татар поэзиясенә нигез салучыларның тагын берсе – үзенчәлекле шагыйрә Халисә Мөдәррисова. «Халисә Мөдәррисова шигърияткә утлы һәм давыллы йөрәге белән килде. <…>. Шагыйрәнең шигырьләре, чын шагыйрьләргә хас булганча, эчке каршылыклар белән тулы, ә бу каршылыклар бик тә саллы һәм оригиналь поэтик образлар аша гәүдәләнә» [9, 12–13 б.]. Татарстанның халык шагыйре Р. Гаташ та бу иҗат әһеле каләменең индивидуальлеген күрсәтә [10, 8 б.]. И. Ихсанова Х. Мөдәррисованың «Баланнар» шигырен шушы ноктадан бәяләп, «кып-кызыл балан тәлгәшләре» символының аерылу-өзелү мәгънәсен белдерүгә хезмәт итүен яза [40].

| | |
|---|---|
| *Йөрәк төсле кызыл*<br>*балан,*<br>*Каерып сындыралар.*<br>..................................<br>*Буш хыяллар коела ул,* | *Аларны*<br>*сындырмаслар.*<br>*Балан төсле күңел*<br>*була,*<br>*Аларны*<br>*тындырмаслар...* [11,<br>6 б.]. |

Шагыйрә иҗатында балан образының мәгънәви вариацияләре С. Сафуанов тарафыннан билгеләнә: «Бер шигырьдә ул – инде җиткән, хәзерге вәхши заманыбызда явыз куллар тарафыннан пычратылу куркынычы алдында калган кыз булып күз алдына баса, икенчесендә тәү кат яры үпкән сылу кызны хәтерләтә, өченчесендә – куаклыкта кызарган балан “кан сарган яңа яра кебек”» [28, 364 б.].

Х. Мөдәррисованың бер төркем әсәрләрендә хатын-кыз тормышта, мәхәббәттә бөек зат, хәтта тынычлык, иминлек сакчысы буларак сурәтләнә. Шагыйрә лирикасы гомумкешелек мотивлар белән генә чикләнми, аның 1980 еллар поэзиясендә иҗтимагый-сәяси мотивлар калкулана. «Туган җирдәге илле илсезлек, телле телсезлек» мотивы лирик герой драматик кичерешләренең сәбәбен билгели: *Сөекле зат булалмадым Синдә, / Ни кылсам да, күңел кителде, / Үз өендә үги ана белән / Үсеп килгән бала шикелле* [10, 90 б.].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: икенче буын шагыйрьләре иҗатындагы социаль-сәяси мотивлар тагын да үстерелеп, иҗтимагый күренеш төсен ала, ике республика җитәкчелеген Башкортстан татарларының рухи-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен конкрет гамәлләр кыла башлауга этәргеч бирә.

1980 еллар ахырында Башкортстанда башланган татар милли хәрәкәте төбәк татар шигърияте барышына да йогынты ясаган уңай нәтиҗәләргә китерә. «1991 елда дәүләт хисабына – "Өмет" яшьләр газетасы, 1994 елда "Тулпар" әдәби-нәфис журналы чыга башлады. Аның битләрендә канат ныгыткан авторлар бүген Башкортстандагы татар әдәби барышының әйдәп баручы көчләрен тәшкил итә» [34, 65 б.]. 1993 елда Башкортстан Республикасының татар телле язучылар берлеге оеша. 1994 елның 10 апрелендә аның I съезды уза. Җыенда оешманың идарәсе сайлана. Рәис вазифасы филология фәннәре докторы, профессор Рәиф Әмировка йөкләнә. 2000 елның 1 гыйнварына оешмада 35 әгъза исәпләнә [41, 89 б.]. 1993 елның октябрь–ноябрь айларында Башкортстан Язучылар союзында татар телле язучыларның рәсми иҗади берләшмәсе оештырыла. Берләшмәнең Нәҗип Асанбаев, Марат Кәримов, Азат Магазов, Таһир Таһиров, Мөкәрәмә Садыйкова, Суфиян Сафуанов кебек тәҗрибәле әдипләрдән торган ун кешелек бюросы сайлана. Берләшмәнең беренче җитәкчесе итеп шагыйрь Равил Шаммас тәгаенләнә. 1995 елдан 2000 еллар башына кадәр бу вазифаны шагыйрь Муса Сираҗи башкара [42, 357 б.].

1994 ел башында Башкортстан «Китап» нәшриятында «Башкортстан халыклары әдәбияты секторы» оештырыла. Нигездә, ул татар телендәге матур әдәбият, дәреслекләр һәм уку кулланмалары чыгару белән шөгыльләнә. 1994 елның 3 февралендә сектор әзерләгән беренче китап – Марис Назировның татар телендәге «Янә утларга керәм» [12] җыентыгы басылып чыга [43, 16–17 б.]. Ул вакытта Башкортстан Язучылар берлеген җитәкләгән шагыйрь һәм галим Равил Бикбаев 1994–1996 еллар аралыгында нәшриятта татар телендә 8 шигырь китабы дөнья күрүен билгели [42, 349 б.]. 1994–2005 елларда барлыгы «татар телендә 133 басма, шул исәптән 97 әдәби китап һәм 36 дәреслек нәшер ителә» [44, 57 б.]. «2016 ел башына әлеге нәшриятта татар телендә барлыгы 210 китап басылып, шуларның 115е – шигърият, 83е проза жанрларына карый. Шул исәптән, сектор оештырылгач, 1994 елдан алып бүгенге көнгә кадәр төрле әдәби жанрларны берләштергән 12 җыентык та татар телендә басылып чыккан» [34, 66 б.]. Әлеге сыйфади үзгәрешләр 1990 еллар уртасына Башкортстанда үз моңы, үз аһәңе, үзенчәлекле сыйфатлары булган татар шигърияте формалашуга китерә.

«Нинди генә әдәбиятны алып карамыйк, аның нигезендә халык мәнфәгатен алга кую – тормыш-көнкүрешен яктырту, рухи дөньясын, язмышын кайгырту, проблемаларны гомумкешелек кыйммәтләре яктылыгында чишәргә омтылу ята» [2, 104 б.], – дип яза Л. Ваһапова. Алар 1990 елларда Башкортстандагы татар шигъриятенең үзәген билгели. М. Нәзировның туган җир, Ватан тойгысын гәүдәләндергән шигырьләренең стиле гадилеге, самими җылылыгы, поэтик сурәтнең ихласлыгы белән аерылып тора [22, 77 б.]. Тикшеренүчеләр хезмәтләрендә М. Нәзировның беренче шигырьләрендә үк күзәтелгән туган җир, туган тел мотивларының үзәктә торуы билгеләнә. Алар М. Нәзиров шигъриятенең лирик герой кичерешләре палитрасын баетудан тыш, шагыйрь тормышына да йогынты ясый, «шагыйрь бу тойгыларның кайсы да булса берсен алдын күреп, икенчесенә хыянәт итә алмады. Нәтиҗәдә ул да озак еллар "Кызыл таң" гәзитенең генә шагыйре булып кала килде. Казан өчен ул – Башкортстан әдибе, ә башкорт әдәбияты дөньясы өчен – татар шагыйре булып исәпләнде» [29, 4 б.].

Шагыйрь күңелендәге туган җир тойгысы белән татар теле һәм әдәбиятының үзәге булган Казанга омтылу теләге арасында барган көрәш М. Нәзировның «Йорт казлары» [12, 36–37 б.] шигырендә аеруча калку һәм образлы гәүдәләнеш таба. Шагыйрьнең драматик кичерешләре антитеза алымы ярдәмендә тирәнәйтелә: «канатларны көчле кагып», «җырлап», «әллә кайларга» очкан ирекле кыр казларына, алар артыннан омтылып, «канатканчы канат кагып», «чабып» йөргән йорт казлары каршы куела:

| | |
|---|---|
| *Омтылганда болытларга,*<br>*Бәреләләр кыекларга.*<br>*Кереш чөйгән таш-ук сыман*<br>*Төшү белән килеп җиргә,*<br>*Каурыйларын чәчеп җилгә,* | *Ыңгырашып, сыкрап, елап,*<br>*Ярсып, соңгы көчне җыйнап:*<br>*Каңгылдыйлар:*<br>*Кыйгак-кыйгак...* [12, 36–37 б.] |

Әдәбият галиме Р. Әмиров карашынча, бу әсәрдә «киек казлар дөньясы – күкләр, җырлар,

киңлек һәм горур тынычлык; йорт казларының мохите – җир, чикләре – йорт-кура, моңнары – ярсу-үксү, аһ-зар. Әмма <…> бу ике дөнья бер-берсенә каршы куелмый, үзара чәкәштерелми, чөнки мәгънә эчтәлеге башка булса да – тавышлар бер, тәгаенләнеше белән аерылса да – канатлар бер. Тик лирик геройның күңеле генә, романтик омтылулар яныннан үтеп, йорт казларына табан юл ала» [30, 99 б.] Әсәрдә кыр казлары һәм йорт казлары янәшәлеге ярдәмендә шагыйрь ясалма чикләр аркасында икегә бүленгән татар дөньясын, Башкортстанда яшәүче татарларның рухи фаҗигасен, үзенең күңел драмасын тетрәндергеч итеп, образлы сынландыруга ирешә. Шигырьнең соңгы строфасы моны укучыга бар тулылыгы белән ачып сала: *Казлар, казлар, аңлыйм сезне, / Мин кушылам сезнең зарга. / Очмыйча син түзеп кара / Иңнәреңдә канат барда. /...Яшәп кара* [12, 36–37 б.] «Марис Нәзиров шигырендәге коллизия, <…> мәдәни-әдәби тормышта урын алып, халкыбызның рухи үсешен тышаулап торган бер җитди социаль күренешкә беренчеләрдән булып ишарә ясый» [30, 100 б.].

Гадилектән катлаулыга бару, фәлсәфилек М. Закиров иҗатының бер үзенчәлеге булып тора [2, 104 б.]. Л. Ваһапова фикере шагыйрьнең каләмдәше Р. Тимершин тарафыннан ныгытыла: «Башкалар күрмәгәнне күрү һәм гади генә күренештән көтелмәгән фәлсәфи фикер чыгару – шагыйрьнең осталыгы» [13, 4 б.]. Символик образга төрелеп бирелгән фәлфсәфи фикер тирәнлеген М. Закировның ике юллык «Шагыйрь» шигыре ачык дәлилли: «*Әле кабере юк, / шуңа кадере юк*» [45, 16 б.]. Әлеге икеюллык халык шагыйре Н. Нәҗми күңелендә зур эмоциональ кичерешләр тудыра.

М. Закировтагы фәлсәфи тирәнлек тормыш тәҗрибәсе, язмыш сынаулары белән бәйләнгән. Бик яшьли әтисез калу ачысы, балачактагы югалтулар, тормыш авырлыгы, хисләр киеренкелеге киләчәктә шагыйрь кулына каләм алырга этәрә. *Дүрт яшьтән үк әтисез бу дөнья, / Ахрысы, ул эзсез узмаган. / Мин дүрт яшьтән ятим, кырыгында / Ятим калганнарны кызганам* [13, 162 б.]. Бу тема шагыйрьнең «Авылдашка хат» поэмасында «шигърият – язмыш» параллеле. ярдәмендә тагын да үстерелә: *Нигә язам?.. Ә нигә язмаска?! / Бу гомерем башы, язмышым. / Шигырь язып була. Ә шигърият / Язмышлардан башка бармы соң?* [14, 108 б.]

Тәнкыйтьчеләр фикеренчә, «Мөхәммәт Закиров шигърияте гадилеге, халыкчанлыгы белән аерылып тора, <…> шагыйрь каләме күп очракта туган як, туган йорт, туган ил, туган тел кебек изге төшенчәләргә зур урын бирә. Әлеге төшенчәләрне М. Закиров Бөек Ана концепциясе аша ача» [2, 104 б.]. Поэтик образлылыкка шагыйрь Ана белән сөйләшү аша ирешә: *Нинди кайгыларың бар соң, әнкәй, / Үксетерлек сине төшемдә?* [13, 20 б.]. Шул рәвешле, яшәеш чыганагы, тормыш дәвамы, гомер һәм яшәү учагын саклаучы, яклаучы, туган җирнең тарту көче булган Ана образы туа. Анадан алган моңны, илаһи нурны кешеләргә өләшүче лирик герой бу очракта үткән белән киләчәкне тоташтыручы, буыннар бәйләнешен тәэмин итүче ролендә килә. М. Закиров шигърияттендә Ана образы туган ил, туган авыл образларыннан аерылгысыз. Автор, «Пәйгамбәрләр» [13, 27 б.] шигырендә ата-бабалардан калган рухи мирасны, тормыш тәҗрибәсен туплаган авыл картларының сафлары сирәгәя баруын күреп, аларны эңгердә югалган «пәйгамбәр»ләргә тиңли. «Югалтмагыз, авылдашлар» [13, 28 б.] шигырендә исә, үзе дә алар артыннан шушы эңгерләргә кереп, «каты бәгырьле» шәһәр чынбарлыгыннан котылырга тели. Тикшеренүчеләр билгеләвенчә, «әнә шул авыл гаме, җирле халыкның психологиясе, җор теле, фикер аныклыгына ия тезмәләр, бер-берсенә бәйләнеп, каләм иясенең иҗат концепциясен хасил итә» [46, 60 б.].

For the first time, the prose of Amirkhan Eniki was presented to the public in 1987 by the story "Reshe" ("Haze") (1962) entitled "Kurkam min bu bakhettan" ("I Am Afraid of This Happiness") on the stage of the Tatar Theater, the Tatar State Theater of Drama and Comedy named after K. Tinchurin. The performance was directed by P. Isanbet and staged by N. Shaikhutdinov and M. Zabbarov. In the stage version, the concept of the writer has been preserved and the poetics of the story remains unchanged. In the same theater, in 2018, the story "Golandem tutash hatirase" ("Memoirs of Gulyandam Tutash") was staged by director R. Zagidullin, staged by I. Gali. Preserving the romantic motif of the story in the dramatization, the authors have somewhat departed from the idea to show the main character as a historical personality. In 2011, the play "Tormish Koraby" ("The Ship of Life") was presented at the Almetyevsk State Tatar Drama Theater, based on the writer's stories "Shayaru" ("To Joke"), "Tynychlanu" ("Calm Down"), "Tonge Tamchylar" ("Night Drops"), "Maturlyk" ("The Beauty"), "Ber suz" ("One Word"), "Mandarin Satuchy" ("A Tangerine Seller"). However, here the motifs of A. Eniki's stories have been changed, the ideas in the writer's works are completely unrecognizable. In the Tatar State Academic Theater named after G. Kamal, A. Zabbarov first turned to the work of A. Eniki in 2022. He was the director and the author of the dramatization of "Reshe" ("Haze"). The concept of the story and the author's message are presented to the viewer in a new way due to individual poetic features. To mark the writer's anniversary in 2019, the story "Reshe" ("Haze") was staged by the youth theater "Mizgel" ("A Moment") of Kazan University. For the youth audience, it was the love story, described in Eniki's work, that was performed.

## Conclusions

The need to stage classical texts has prompted a repeat performance of A. Eniki's works on the stage of the Tatar theater. The prose of Amirkhan Eniki is a complex, peculiar epic material, complicated enough for its translation into the stage language. The director and the dramatist should not limit themselves to reading his works, but should learn to feel the language and the style of the writer. When staging Eniki's novels and stories, they should preserve the language of A. Eniki's works as a unifying aspect in all stagings. However, the dramatized versions of A. Eniki lack the grandiosity of the ideas that he wanted to convey to his reader. The characters often tell their love stories, but this love does not rise to the heights of a philosophy of being that educates and makes a person feel proud, determining his fate. The viewer, who has read the books and fallen in love with A. Eniki, does not feel the subtleties of the writer's works in the stage versions. The stage of the Tatar theater

can offer successful performances if it thoughtfully approaches the works of Amirkhan Eniki with their special spiritual and scientific background.

**References**

1. Zabbarov, M. (2006). *“Mina “teatr zhene” gomerlekka kagylgan. Sakhnadan kitsam da, min teatrsyz Yashi almyim* [“The Demon of the Theater” moved into me forever. Even if I leave the stage, I can’t live without theater]. Tatar-inform. Aprel’ 10, 2006. URL: https://tatar-inform.tatar/news/marsel-abbarov-mi-a-teatr-ene-gomerlekk-kagylgan-s-hn-d-n-kits-m-d-min-teatrsyz-yashi-almyym?ysclid=lcoq9fyrd2785878271 (accessed: 09.02.23). (In Tatar)

2. Shaykhutdinov, N., Zabbarov, M. *“Kurkam min bu bakhettan”* [“I Am Afraid of This Happiness”]. Iz personal’nogo arkhiva M. Zabbarova. Rukopis’, napechatannaya na pechatnoy mashinke. 44 p. (In Tatar)

3. Gali, I. *Golandem tutash hatirase* [Memoirs of Gulyandam Tutash]. Iz arkhiva Teatra dramy i komedii imeni K. Tinchurina. Rukopis’ 42 p. (In Tatar)

4. Ismagileva, F. *Tormysh koraby* [The Ship of Life]. Iz arkhiva Almetyevskogo Tatarskogo Dramaticheskogo Teatra. Rukopis’, 20 p. (In Tatar)

5. Minnullin, F. (1994). *Namus eshe* [A Matter of Honor]. F. Minnullin. Balta yavyzlar ulynda: Critics. Pp. 231-244. Kazan, Tat kit.nəshr. (In Tatar)

6. Eniki, A. (2019). *Rasha* [Haze]. Əsərlər: 3 tomda. (Təz. G. R. Gainullina). Pp. 7-176. Kazan, Tat. kit.nəshr. (In Tatar)

7. Eniki, A. *Farida Kudasheva turynda bernicha suz* [A Few Words about Farida Kudasheva]. Əsərlər: 3 tomda. (Təz. G. R. Gainullina). Pp. 499-501. Kazan, Tat. kit.nəshr. (In Tatar)

8. Idrisov, R. (2019). *Saydash belan Golandem* [Saydash and Gulyandam]. Vatanym Tatarstan. Mart 2 (No. 31), p. 3. (In Tatar)

9. Gimadova, G. (2018). *Tinchurin teatry muzykal asar kuidy* [The Tinchurin Theatre Has Staged a Musical]. Vatanym Tatarstan. Mart 2 (No. 161), p. 18. (In Tatar)

10. Sultanova, F. (2015). *Soyla, Golandem…* [Tell Gulyandam]. Beznen miras. No. 5, pp. 104-111. (In Tatar)

11. Gilmetdinova, A. (2019). *Rasha* [Haze]. Sakhna. No. 6, pp. 28-30. (In Tatar)

12. Safina, L. (2022). *Rashale Donya* [The World in Haze]. Vatanym Tatarstan. Dekabr’ 28 (No. 193), p. 3. (In Tatar)

13. Galimullina, M. (2023). *Rasha gena bulyp kalgan “Rasha”* [“Haze”, Which Remained Just Haze]. Madani zhomga. Gyinvar 13 (No. 1), p. 5. (In Tatar)

14. Khabutdinova, M. M. (2023). *Marevo* [Haze]. Zvezda Povolzhya. Fevral’ 11-17 (No. 5 (1115)), pp. 1-5. (In Russian)

15. Akhatova, B. (2022). *Skvoz' Marevo* [Through the Haze]. Respublika Tatarstan. Dekabr’ 27 (No.193), p. 39. (In Russian)

16. Karamova, A. (2004). *Vneshnee proyavlenie vnutrennego sostoyaniya geroya v povesti A. Eniki «Marevo»* [The External Manifestation of the Protagonist’s Inner State in the Story “Marevo” by A. Eniki]. No. 6, pp. 25-27. (In Russian)

17. Gabashi, A. (2012). *Tormysh kitaby* [The Book of Life]. Sakhna. No. 4, p. 14. (In Tatar)

18. Motigullina, A. (2009). *Khatiralar yanarganda* [When Memories Renew]. Yashlek Tavyshy. No. 3 (23), p. 5. (In Tatar)

19. Eniki, A. (2019). *Golandem tutash hatirase* [Memoirs of Gulyandam Tutash]. Əsərlər: 3 tomda. (təz. G. R. Gainullina). Pp. 398-556. Kazan, Tat.kit.nəshr. (In Tatar)

20. Gimranova, D., Tagirova, A., Ismagilova, F., Mukhammetzyanova, M. (2014). *Almat tatar daulet drama teatry.* [The Almetyevsk Tatar Drama Theater]. 304 p. Kaza, Foliant. (In Tatar)

# ТАТАР ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ ӘМИРХАН ЕНИКИ ӘСӘРЛӘРЕ

**Гөлфия Расил кызы Гайнуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
gulfiarasilevna@mail.ru.

Мәкаләдә Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Әмирхан Еники әсәрләренең татар укучысына театр сәнгате аша ирешү тарихы һәм үзенчәлекләре өйрәнелә. Әдипнең прозасы тамашачыга татар театрлары сәхнәсеннән даими тәкъдим ителеп килә. К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры 1987 елда Ә. Еникинең «Рәшә» (1962) повестен «Куркам мин бу бәхеттән» дигән исем белән (режиссеры П. Исәнбәт, инсценировка авторлары Н. Шәйхетдинов һәм М. Җәббаров) һәм 2018 елда «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) повестен шул ук атама белән (режиссеры Р. Заһидуллин, инсценировка авторы И. Гали) сәхнәгә куя. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Ә. Еники иҗатына беренче тапкыр 2022 елда мөрәҗәгать итә һәм «Рәшә» повестен сәхнәләштерә (режиссеры һәм инсценировка авторы А. Җәббаров). Шул ук әсәрне әдипнең юбилее уңаеннан 2019 елда Казан

университетының «Мизгел» яшьләр театры да куя (режиссеры һәм инсценировка авторы И. Хафизов). Аңа кадәр режиссер М. Җәббаров та, «Мизгел» театрындагы яшь артистлар белән эшләгән елларында, Ә. Еники прозасына даими мөрәҗәгать итә, әдипнең «Әйтелмәгән васыять» һәм «Йөрәк сере» әсәрләрен язучының үз үтенече белән сәхнәләштерә. Әлмәт Татар дәүләт драма театрында язучының «Шаяру», «Тынычлану», «Төнге тамчылар», «Матурлык», «Бер сүз», «Мандарин сатучы» хикәяләренә нигезләнеп эшләнгән «Тормыш корабы» спектакле (режиссеры Гүзәл Акбердина, инсценировка авторы Фәридә Исмәгыйлева) куела.

Фәнни мәкаләдә бәяләү объекты – Ә. Еникинең «Рәшә» һәм «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьларының шул исемдәге инсценировкалары һәм әдипнең хикәяләрендәге мотивларга таянып эшләнгән «Тормыш корабы» инсценировкасы. Тикшерү предметы булып язучы һәм режиссер тәкъдим иткән текстларның идея-эстетик сыйфатлары, сәхнәләштерү үзенчәлекләре, алымнары, әсәрләрдәге тирән фәлсәфи-әхлакый фикерләрнең тамашачыга җиткерелү алымнары тора. Шулай ук спектакльләрнең куелу тарихлары, төп һәм аларны ачарга ярдәм иткән икенчел дәрәҗәдәге геройларны башкарган актерлар, аларның сәхнә осталыгы мәсьәләләре дә гыйльми язманың тикшерү предметын һәм яңалыгын билгели.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, театр, мәдәният, Әмирхан Еники, повесть, спектакль

## Кереш

XX йөзнең икенче яртысы татар прозасының йөзек кашы Әмирхан Еники (1909–2000) әсәрләре татар укучысы һәм тамашачысына театр сәнгате телендә дә барып ирешә. Соңгы дүрт дистә елда бу өлкәдә режиссерлар Празат Исәнбәт, Марсель Җәббаров, Наил Шәйхетдинов, Рәшит Заһидуллин, Айдар Җәббаров, Гүзәл Акбердина, Илфак Хафизов исемнәрен аерып билгеләү зарур. Яшь режиссер М. Җәббаровка әдип заманында үзенең повестьларын сәхнәдә күрү теләген җиткергән була [1]. Язучының психологизмга корылган эпик текстын сәхнә теленә күчерү – гаять катлаулы эш. Әмирхан Еникинең татар театры сәхнәсендә тәүге тапкыр куелуы Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер Празат Исәнбәт исеме белән бәйле. Яшь актерлар Н. Шәйхетдинов һәм М. Җәббаров «Рәшә» повесте мотивлары нигезендә «Куркам мин бу бәхеттән» дип исемләнгән инсценировка язарга алыналар. Әйтергә кирәк, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты М. Җәббаровның сәхнә теленә күчергән беренче әсәре Әмирхан Еники повесте була. Инсценировка тексты белән танышканнан соң, әдип үзе аны бер төзәтмәсез кабул итә һәм сәхнәгә куярга ризалык бирә [2, 1 б.]. К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры 1987 елдан соң әдип иҗатына 2018 елда янәдән мөрәҗәгать итә. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең атказанган артисты, ул вакытта театрның баш режиссеры Рәшит Заһидуллин Ә. Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» романтик повестен беренче тапкыр сәхнәгә күтәрә. 2022 елда яшь режиссер Айдар Җәббаров язучы иҗатын Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куюга алына. «Рәшә» повесте нигезендә язылган инсценировканың башлам өлешенә әдипнең «Бер генә сәгатькә» хикәясенең дә сәхнә телендә бик урынлы яңгыраш алуы игътибарга лаек. М. Җәббаров «Мизгел» яшьләр театры белән әдипнең тагын ике повестен сәхнәләштерә. Соңрак яшь режиссер И. Хафизов, остазы М. Җәббаровны дәвам итеп, «Рәшә» повестена мөрәҗәгать итә. 2011 елда Әлмәт Татар дәүләт драма театрында Г. Акбердина, әдип хикәяләрендәге мотивларга таянып, «Тормыш корабы» спектаклен тәкъдим итә. Күренгәнчә, җөмһүриятебездәге данлыклы өч театр һәм Казан университеты сәхнәсендә тамашачы хөкеменә әдипнең җәмгысе өч повесте, җиде хикәясе тәкъдим ителә.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Фәнни тикшеренү материалы буларак Ә. Еникинең «Рәшә» (1962), «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) повестьлары, алар нигезендә язылган М. Җәббаров һәм Н. Шәйхетдиновларның «Куркам мин бу бәхеттән» (1987), И. Галинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» (2018) инсценировкалары ([2], [3]) һәм А. Җәббаровның «Рәшә» (2022) һәм «Шаяру», «Тынычлану», «Төнге тамчылар», «Матурлык», «Бер сүз», «Мандарин сатучы» хикәяләренә нигезләнеп эшләнгән «Тормыш корабы» (2011) [4] инсценировкалары алынды. Тикшеренү методлары һәм принциплары гыйльми эзләнүнең максатына һәм өйрәнү объектына нигезләнеп сайланылды. Әдәби иҗатны, әсәрне шәрехләү һәм анализлауның мәдәни-тарихи, чагыштырма-тарихи методлары файдаланылды.

**Фикер алышу**

Үзе исән вакытта ук әсәрләре классик әдәбият сыйфатында бәяләнгән Ә. Еники прозасын өйрәнүгә әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр һәрдаим игътибар бирә. Профессиональ тәнкыйтьче Ф. Миңнуллинның «Әмирхан Еники әсәрләре безнең тәнкыйтькә кызу бәхәсләр, капма-каршы фикерләр кузгатып килде» [5, 231 б.] дигән фикере бүген дә актуаль. 1964 елгы «Намус эше» исемле мәкаләсендә тәнкыйтьче «Рәшә» повесте турында әдипнең үзе белән әңгәмәсеннән өзекләр китерә: «Рәшә» – зөфәрләр турындагы повесть. Зөфәр Сабитовны Сез кайдан, ничек табып алдыгыз?» дигән сорауга җавап биреп, Ә. Еники болай яза: «Зөфәр Сабитовны табуы читен булмады. Алар бар иде һәм хәзер дә беткәннәре юк, минемчә. Ләкин Зөфәр кебек кешеләр бары сәүдә-тәэминат тирәсендә генә йөриләр дип уйламаска кирәк… Хикмәт бит профессиядә түгел, ә кешенең фәлсәфәсендә…» [5, 235 б.]. Тәнкыйтьче, фикерен үстереп, повесть рус телендә басылганнан соң, Г. Куклисның «Литературная газета»ның 1975 елгы 7 февраль санында дөнья күргән «Әмирхан Еникинең күп төрле сыйфатлары» мәкаләсендәге сүзләренә мөрәҗәгать итә: «Милли әдәбиятларда мондый характерның очраганы юк иде шикелле, ул – язучының ачышы» [5, 239 б.].

Димәк, Әмирхан Еникинең төп максаты – «кешенең фәлсәфәсен» ачып бирү икәнлеге аерымачык. Авторның төп фикере, әдәби барышта үз чорының ачышы булган төп герой Зөфәр Сабитов сәхнә телендә ничек тәкъдим ителә соң?

Повестьның үзендә вакыйгалар вакыты 1945 елның тугызынчы мае дип тарихи билгеләнеш ала. Хикәяләүче Бөек Җиңү иртәсендә уяныргa һәм юл сайларга тиешле Зөфәр Сабитовны тәкъдим итә. Геройның эчке халәтен сөйләп бирү өчен кулланылган төш алымы белән автор укучыны сюжетка керергә әзерли. Төш эчендәге символлар аша Зөфәр күңелендәге төшенкелек халәте – аның өчен даими халәт икәнлеге аңлашыла: *«Дала буш, дала тын, үзе тип-тигез, очсыз-кырыйсыз»* [6, 7 б.]. Геройның тормышында көтелмәгән, әмма җитди үзгәреш булачак: *«Бик эссе, бик коры, төпсез күктән кызган тимердәй ап-ак кояш аның күзенә туры карый...»* [6, 7 б.], ирне шул борчый («тере кояш… бервзлексез яндыра, көйдерә, имеш»). Шул ук вакытта ул бу халәтеннән («котсыз дала» символик детале) котылуны тизләтергә ашыга: *«Кая бара ул, мәгърипкәме, мәшрикъкәме – ачык кына белми дә, имеш, ләкин барырга кирәк, бармыйча ярамый, чөнки монда туктап калу һич мөмкин түгел»* [6, 7 б.]. Аң агышы алымы белән бирелгән сурәт ярдәмендә авторның һәркем үз бәхетенә юлны үзе эзли һәм таба дигән карашы укыла: *«Һәм берәүгә дә әйтмичә, берәүне дә ияртмичә, ялгызы гына чыгып китүе дә бары шуның өчен генә, имеш»* [6, 7 б.].

Наил Шәйхетдинов белән бергә язылган «Куркам мин бу бәхеттән» инсценировкасындагы Марсель Җәббаров үзе уйнаган Зөфәр, Илфак Хафизовның «Рәшә»сендәге һәм Айдар Җәббаров иҗат иткән Зөфәр дә повестьтагыча тәкъдим ителә: «Зөфәр өчен бер хакыйкать көн кебек ачык иде: сугышта исән калу факты үзе генә дә кешегә: «Бәхетлемен!» – дип әйтергә хокук бирәчәк… Ләкин Зөфәргә хәзер бу бәхет кенә аз иде инде. Ул – реалист, аныңча, баш исән булу гына чын бәхет түгел әле. Исән калган баш ничек яшәр – менә хикмәт нәрсәдә. Ә ул моның серен белә инде: бәхет – үзең теләгәнчә яшәү, бәхет –матди һәм рухи бәйсезлек ул. Бәс, шулай икән, Зөфәр дә киләчәк тормышын үзе теләгәнчә бәйсез, иркен, мул итеп корып җибәрергә тиеш. Һәрхәлдә, ул бөтен көчен, сәләтен җигеп, шуңа омтылырга тиеш. Моның өчен хәзер аңа ике конкрет мәсьәләне тизрәк хәл итәргә кирәк булачак. Берсе – акчаны малга әйләндерү, ягъни йортмы-квартирамы сатып алу; икенчесе – аңа терәк һәм теләктәш булырлык әйбәт кенә кызга өйләнү… » [2, 24 б.].

Повесть нигезендә язылган бер инсценировкада да урын алмаган әһәмиятле символларга игътибар итик. Язучы Зөфәр халәтендәге үзгәрешнең инде озак вакытлар әзерләнеп килүен кояш образының эчтәлегенә салып сөйли. Зөфәр әлеге үзгә халәтнең барлыгын таный (ул аңа *«юлдашка эт шикелле иярген гамьсез кояш»* кебек), әмма гамьсез генә яши дип бирә: *«Баштарак аңа тигез дала буйлап атлавы бер дә күңелсез, авыр булып тоелмады. Киресенчә, бу иркенлектә, бу тынлыкта бару рәхәт тә кебек иде»* [6, 7 б.]. Гамьсезлек һәм икейөзлелек – кешедәге якты, җылы хисләрне үле хәлгә китерергә сәләтле халәт, тора-бара ул шом тудыра, ди автор Зөфәр сайлаган юлның дәвамын тасвирлап (*«Ләкин тора-бара очы-кырые күренмәгән үлек дала аны борчый, шомландыра башлады»* [6, 7 б.]). Зөфәр әле үзгәрергә әзер түгел. Үзен-үзе аңламаган Зөфәр нәфрәтләнә: *«Тагын шоп-шома күктән шым*

*гына ияреп барган «юлдашы да» бик мәкерле, явыз булып чыкты. Хәзер ул Зөфәрнең нәкъ менә баш түбәсен кыздыра, шундый кыздыра, әйтерсең, юри кайнатып чыгарырга тырыша...»* [6, 7 б.]. Автор ирнең чарасызлык хәлендә калуын – сусавын тасвирлый: *«Атлаган саен көчәя барган бу сусауга һич кенә дә түзәрлек түгел иде, коточкыч авыр иде, чатнап кара янган иреннәре бертуктаусыз: „Су... су... су... !“ – дип үзлегеннән кыймылдый иде»* [6, 7 б.]. Димәк, яшәү символы кебек укылган су символы ярдәмендә автор Зөфәрдә туган яңа омтылышны – башкача яшисе килү теләген тасвирлап бирә. Күл – «шашарга җиткән» Зөфәр каршында пәйда булган, ул теләп чакырган яңа чынбарлык, бәхет, чарасызлыктан котылу гәүдәләнеше: *«... кинәт җем-җем уйнаклап яткан түп-түгәрәк, зур бер күл ачылды... Бу шулкадәр чын иде, шулкадәр якын иде, гүя менә суның йомшак дымы аның йөзенә килеп тигәндәй булды»* [6, 8 б.]. Биредә Ә. Еникинең 1941 елгы хикәяләреннән үк ачык яңгырап килгән яшәеш фәлсәфәсе укыла: өметсезлек алдында калган кешегә тормыш-яшәеш һәрчак үзгәрү, дөрес юлга чыгу мөмкинлеге бирә. Язучы карашынча, һәр кешегә үзенә тиешле чынбарлыкны кору мөмкинлеге бирелгән, көч салынган, ләкин әлеге потенциалны эшкә җигәргә комачалаучы җимергеч көч – курку хисе аңны томалый.

Шул рәвешле, *кояш, дала, су* символларына сәхнә текстында әһәмият бирмәү 2022 елгы куелышта актер Алмаз Борһанов уйнаган Зөфәр Сабитовны «кешенең фәлсәфәсен» бирерлек тирәнлектән мәхрүм итә, димәк, алда әйткән автор фикере дә үзгәртелә. Айдар Җәббаровның Зөфәре исәп белән яшәргә мәҗбүр булуны хәтта каһкаһәле тантана белән җиткергән булдыклы вак сәүдәгәр образы гына булып калка. Әйтергә кирәк, тамашачы Алмаз Борһановның Зөфәрендә гамьсезлек, икейөзлелек, курку халәтенең аның даими халәте, җимергеч көч икәнлеген танып ала! Ләкин сәхнә бизәлешендәге модернистик эстетика Ә. Еники тудырган Зөфәр фәлсәфәсен җиткерүгә хезмәт итми.

Повестьтагы Зөфәр җиңү бәйрәмендә кызу эштә: *«бу көнне күтеп складларда саклап тоткан»* [6, 9 б.] азык-төлекне чыгарыр вакыт җитте бит, *«сәүдә точкаларына шалтырата башлауга» «бәйрәм настроениесе гүя тышта торып кала»* [6, 9 б.]. Айдар Җәббаровта бу сызык аерым детальләр өстәлсә дә тотып алынган. Йөрәген шом, курку өткән Зөфәр ашык-пошык сәүдә точкаларына товар (ни өчендер аны режиссер аракы детале белән чикләргә уйлый) озату белән мәшгуль. Ә Наил Шәйхетдинов, Марсель Җәббаров һәм Илфак Хафизов инсценировкаларында бу өлеш юк.

Тексттагы тагын бер момент әһәмияткә ия. Зөфәр *«эшкә барса да, бәйрәмчә булсын дип, чиккән якалы ак күлмәген, элүдә генә торган соры костюмын, җәйге туфлиләрен киде. Барысы бер төстән, бер иштән диярлек, тик менә зәңгәр кепкасы гына күренешне боза иде. Ярый инде, баштанаяк бертөследән киенер вакытлар алда әле...»* [6, 9 б.]. П. Исәнбәт персонажының тышкы рәвеше инсценировкада билгеләнмәгән. Айдар Җәббаров исә повестьтагы бу сурәткә әһәмият бирми. Артык фырт киенгән Зөфәр зәвыклы тамашачыда шик уята. Чынлап та, Бөек Ватан сугышы беткән елмы бу? Алай икән, үзе сугышта катнашкан Әмирхан Еники эшләгән Зөфәр портретымы бу? Зөфәрнең тышкы кыяфәте – тулаем режиссер уйдырмасы. Димәк, автор тудырган Зөфәргә режиссер яңа штрихлар кертә, яңа мәгънә төсмере өсти. Кертелгән мәгънә төсмере ышандырамы, монысы башка мәсьәлә. Тамашачының Еники образларын төптән белмәгән катламын бу портрет бөтенләй башка эзгә алып чыкмыймы? Монысы инде Айдар Җәббаров җаваплылыгында. Илфак Хафизовның Зөфәре бу җәһәттән Ә. Еники текстына туры килә.

Ә. Еникидә чит / үз бинар оппозициясе белән бирелгән Зөфәр халәте барлык режиссерлар тарафыннан да тотып алынган. А. Җәббаров һәм И. Хафизов Зөфәрнең сугыш вакытындагы һәм сугыштан соңгы халәтендәге аерманы ассызыклауны кирәк таба. Зөфәрнең сугыш беткәннән соңгы халәте тексттагыча аермачык билгеләнә: *«бүгенге көннән ул берәүдән дә шүрләмичә, һәркемнең йөзенә туры карап йөри алачак»* [6, 10 б.]. Зөфәрдәге куркуның сәбәбе – *«бөтен кеше тегендә, ут эчендә, ә ул тап-таза килеш монда йөргәнгә» «башкаларның ят итеп, дошман итеп караулары»* [6, 10 б.]. Текст буенча кешеләр кыю, бәйсез, кулсыз майор Симаковны якын итә. Зөфәрдәге курку аны әлеге «кулсыз»ларны үз итә торган чит тирәлек белән сак булырга өнди, ул үзенә (киеменә) төс булмаган зәңгәр кепкасын күтәрә төшеп, баш иеп узуны» [6, 10 б.] мәслихәт күрә яисә *«кулсыз майор белән очрашуларны яратмаганга»* [6, 10 б.] (дөресе, кирәк санамаганга), әйләнеп уза. Соңрак Курамшин карт белән исәнләшкәндә кул бирмәве дә шул мәгънәне көчәйтеп килә.

Спектакль вариантларында, кызганычка каршы, бу детальләргә игътибар ителмәгән! Алмаз Борһанов тудырган Зөфәрдә Курамшин карт белән кул бирми көрешү моменты сакланган, әмма тиешле мәгънә бирерлек итеп ассызыкланмаган.

Повестьның икенче бүлегендә Рәшидә Сафина дөньясы ачыла. Хикәяләү Зөфәрнең бу хакта искә төшерүе кебек оештырыла. Вакыйгалар башланган вакыт 1943 елның үтә салкын гыйнвар ахырлары дип тарихи вакыт буларак тамгалана. Зөфәрнең *«салкын, караңгы, котсыз, буш»* [6, 16 б.] вокзал эчендә очраткан дүрт кешегә мөнәсәбәте инде гайре табигый тоелмый. Өч инсценировкада да бу өлеш повестьтагыча. *«Яхшы пальто, күн түбәле каракүл бүрек, эт тиресеннән озын кунычлы унты кигән һәм бер беләгенә зәңгәр тышлы бәрән толыбын салып, икенче кулына кара чемодан тоткан, бик тук кыяфәтле, таза егетнең»* [6, 16 б.] *«өсләре бик чуар, бик иләмсез»*, тәпән шикелле юан, сырган чалбарлы, киез итекле, кайсы шәл уранган, кайсы малахай бүрек кигән бу кешеләргә *«нәфрәтләнеп кул селтәве»* дә инсценировка вариантларында тотып алынган.

Әсәр текстындагы тагын бер деталь һәр өч инсценировкада да, үзгәртелмичә, үзенә йөкләнгән идея-эстетик мәгънәне үти. Турайга бару турында һәркем кабатласа да, Зөфәр *«кечкенә коңгырт күзле, олырак, озынрак, өс-башы пөхтәрәк»* [6, 18 б.] Рәшидәне генә ишетә: *«Зөфәр бер мизгел аңардан күзләрен ала алмыйча торды. Әллә ничек менә, кызның бер үк вакытта диярлек бик туры-җитди каравы һәм матур-сөйкемле итеп елмаюы аны гаҗәпләнеп югалып калырга мәҗбүр итте»* [6, 18 б.]. Зөфәр Рәшидәнең *«беренче караштан ук бик самими һәм бик табигый тоелган» дөньясын үз итә. Зөфәргә йөкләнгән ат табу вазифасы спектакль текстларында да уңышлы: «Сез табарсыз, әгәр теләсәгез»* [2, 4 б.]. Рәшидә иргә ышаныч белдерә, йөрәген курку өткән Зөфәрне хатынның самими һәм ихлас ышанычы дәртләндерә. Рәшидә исә Зөфәрдәге ышанычлы ир-ат була белүне үз итә, тансык булганга мавыгып китә. Инсценировкаларда да басым ясалган Рәшидә белән Зөфәрнең кавышу мизгеле – салкын чынбарлыкта югалып алган ике ялгызның җылынырга теләп, ышанычлы иптәш эзләү мәле ул: *«Мин гүя кеше таптым, кешегә сокландым, шул кешенең үзе, җылы-йомшак мөнәсәбәте миңа тансык иде, миңа кадерле иде...»* [6, 171 б.]. Җан тынычлыгына омтылып та, берара кешелек горурлыгы, хатын-кыз горурлыгы, садәлеге өчен җаваплылык хисен югалткан Рәшидә үзенең көчсезлеген аңлый һәм бу чарасызлык халәте аны күңелендә үкенү хисе уяткан ялгыш адымга этәрә.

Өченче бүлек Зөфәрдәге хисләрнең гомумәһәмиятлелеген раслап килү өчен аерып куела. Пространство бирелешенә (*«клуб дигәннәре урамга кырынрак утырган, манарасы киселгән иске мәчет бинасы»* [6, 27 б.]) автор яшәп килүче совет идеологиясенең зөфәрләр фаҗигасе өчен җаваплылыгы эчтәлеген сала, биредә проблема иҗтимагый яссылыкка күчерелә.

Повестьта, артистлар чыгыш ясаганнан соң, авыл кешеләренең кул чапмау детале авыл көе тексты – кешеләр өчен уртак булган хәсрәт хисе бирелеше белән бәйләнештә килә. Әлеге чынбарлык белән килешергә теләмәгән, ләкин килешергә мәҗбүр кешеләр хәсрәте гомумәһәмиятлелек төсен ала:

> «Җыр бетте. Караңгыда утырган халык бер мизгел тып-тын булып торды. Әйтерсең алар хыяллары белән бу иске мәчет эченнән бик ерakka иң кадерле якыннарын, өметләрен, бәхетләрен эзләп киткәннәр иде. Һәм гүя әнә шул ерактагы фронтның карлы далаларына, бозлы сазлыкларына, кара урманнарына барып тапкан, кавышкан газиз якыннарыннан аерыла алмыйча, кире бу салкын ялгызлыкка кайтырга кодрәтләре җитмичә утыралар иде. Әйе, мондый хәлдә ду килеп кул чабу мөмкин дә түгел иде» [6, 28 б.].

Бу өлеш Айдар Җәббаров инсценировкасында уңышлы кертелгән.

Празат Исәнбәт повестьтагы «Тәфтиләү», «Юксыну» җырларын үзгәрешсез калдыра һәм ул режиссерның отышы төсендә бәяләнергә хаклы. Нәкый Исәнбәтләр буыны вәкиле Ә. Еники теле белән әйткәндә, «татар кешесе җырдан иң элек моң көтә, моң ишетергә тели» [7, 499 б.]. Автор Рәшидәдәге матурлыкны татар кешесенең күңелендә сакланган серле моң белән бәйли. А. Җәббаров инсценировканың башлам өлешенә персонаж артистларның «Бер генә сәгатькә» әсәрен уйнауларын өсти, биредә, әйтергә кирәк, соңрак Рәшидә ролен уйнаган Гүзәл Шакированың Заһидәсе дә гаҗәеп ышандыра. Бу очракта һәр режиссер авторның рухи ныклык хакындагы фикерен үзенчә үстерә. Инсценировкаларда авторның әлеге идеясе повестьтагыча Яруллин теле белән ассызыклана: *«Халыкта тормышка мәхәббәт бик зур, менә аның сере нәрсәдә...»* [6, 39 б.]; Рәшидә исеменнән җөпләнә: *«...нинди генә җырны алма, ул барысыннан да бигрәк кеше*

*күңелендә тормышка мәхәббәт уята, кешедә яшисе килү теләген көчәйтә...»* [6, 39 б.]. Тормышны ярату гына хәсрәт-михнәтне кичкәндә юаныч була ала дигән әлеге хакыйкатьне Мәликә әби раслап куя: *«Авыл кешесенең юанычы ни шул җыру инде, белеп сөйлисез»* [6, 39 б.]. Татар кешесенең хәсрәтле чынбарлыкка шөкер итә белүе – үз тормышын хикәя иткән гомер кичкән карчык исеменнән «тормышның үзе кебек чын, гади» киңәше дип билгеләнеп куела: *«Көн итү авыр булса да, барына шөкер итеп торабыз әле, мондый чакта зарлану язык булыр, нишлисең инде!»* [6, 40 б.].

Әсәрдә һәм П. Исәнбәт белән А. Җәббаров эшләгән спектакльләрдә Зөфәрнең йорт алу вакыйгасына аерым игътибар бирелә. *«Ниндидер бик вак купецтан калган»* [6, 69 б.], *«нигез өстендәге бүрәнәләре черегән»* [6, 69 б.] Сабитовларның Суконныйдагы йорты – Зөфәрнең гүя күлгә омтылуы – үзен буып торган, гел исәп-хисапка корылган чынбарлыгыннан качарга, җан тынычлыгына ирешергә теләве сурәте. Шуңа күрә инсценировкаларда күл символын саклау кирәк иде! Зөфәр сайлаган яңа чынбарлык *«борынгы өяз шәһәрендәге шикелле аулак, тын һәм тыныч»* [6, 76 б.]. Повестьта татар иренең аң төпкеленә тирән уелган тыйнак-горур, заман шаукымына буйсынмас асылы ачылырга тиеш, Зөфәрнең эчке омтылышы әнә шул ләбаса:

> «Күптән салынган булуына карамастан, ул, нәкъ яңа йортлардай, ничектер балкып, горур кыяфәт саклап, бик төз, туры утыра. Аннары йорт художество элементларыннан да мәхрүм түгел икән: кәрниз буйлары, тәрәзә башлары, артык чуарланмыйча гына, челтәр өлге белән бизәлгән, ә болдыр баганалары нечкә билләп, гөмбәз чыгарып эшләнгән – болар һәммәсе дә йортка тыйнак бер нәфислек биреп тора…» [6, 76 б.].

Йорт янәшәсендәге бакча – Зөфәрнең *«күптән хыял иткән»* [6, 79 б.] мохите. *«Балачактан ук табигатьне, үсемлекләрне белмичә үскән»* Зөфәргә бакчаның «бик тансык, бик кадерле» булуын белү укучыда иргә карата ихтирам, ышаныч уята: *«Һәм менә хәзер өйнең үзеннән дә ямьлерәк, кадерлерәк төсле булып, аның алдында карт бакча күкрәп тора»* [6, 79 б.]. Инсценировкаларда бу символны калдыру, аңа басым ясау Зөфәр образына салынган фикри тирәнлекне саклап калыр иде. Әйтергә кирәк, идиллик бакча символы Ә. Еники прозасын XX йөз башы татар прозасы белән бәйли, инсценировкалардагы проблеманы иҗтимагый мотивлаштыру шул яссылыкта үзгә тирәнлек алыр иде. Әдип Зөфәрнең үз асылына кайта алмаячагында яшәп килүче совет системасын гаепли:

> «Шушы искергән, картайган, ташландык хәлгә килгән тын бакчадан аңа ничектер борынгы дворян интеллигентының инде мәңге кире кайтмас тормышы аңкыгандай булды. Беркадәр моңсу сагыш белән шул тормышның югалуын кызганып куйды» [6, 80 б.].

Инсценировкаларда Зөфәрнең бары тик гади бер сәүдәгәр образы амплуасында сурәтләнүе иренең үкенечен ироник тантанага әверелдерә. Андый сәүдәгәр чиста күңелле ярлы Рәшидәне үз итә алмый. Ә. Еникинең Зөфәре – горур, ихлас Рәшидә дөньясын чынлап сөя һәм борынгыдан килгән татар көнитешен кадерли алган, үзендә заман шаукымына буйсынмас көч, гайрәт эзләп газапланган булдыклы татар ире. Инсценировка авторлары, кызганычка каршы, символлар артына яшеренгән потенциаль эчтәлекне күреп бетерми һәм фәлсәфи-әхлакый тирәнлектән китә.

П. Исәнбәтнең «Куркам мин бу бәхеттән» инсценировкасында повестьтагы финал үзгәртелми. А. Җәббаров куйган «Рәшә» спектакле ахырында иҗтимагый мотив калкуландырыла, әмма Әмирхан Еники әйтергә теләгән фикер бөтенләй югала. Чөнки А. Җәббаров Зөфәрнең азгын халәтенә артык әһәмият биреп, автор текстындагы геройның үз асылын эзләүче татар ир-аты булуын бөтенләй сызып ташлый. Спектакльдәге Зөфәр – азгын, икейөзле, карак сәүдәгәр. Бу инсценировкада режиссер Ә. Еники калкуландырган *«кешенең фәлсәфәсе»* хакындагы идеядән китә. Рәшидәнең сүзләре хат детале аша кертелә. Сонгы күренештә Рәшидә язган хатны Зөфәр эчке бер ачу, каһкаһәле тантана белән бөгәрләп ташлый:

> «Тип-тигез дала түрендә менә бервакытны ялтырап яткан күл ачыла. Чын күл бу, хәтта җем-җем уйнаклаган вак дулкыннарына кадәр күренә. Менә шуңа карап барасың, барасың, ләкин барып җитә алмыйсың. Чөнки ул юк, ул рәшә генә, коры далада алдап-котыртып уйнаклаган эссе шәүлә генә» [6, 171 б.].

П. Исәнбәт эшләгән спектакльдә повестьтагыча бу сүзләрне Рәшидәдән ишеткән Зөфәр әрни, җиңелгәнен таный, гомерлеккә бәхетсезлеккә дучар ителгәнлегеннән сызлана!

«Рәшә» әсәренең тагын бер сыйфатын ассызыклап үтик. Повестьта Рәшидә образы

ярдәмендә үткәрелгән автор идеясе, бүләк итеп бирелгән маркизет күлмәклек кире кагылганнан соң, Зөфәр әйткән сүзләр аша җиткерелә. П. Исәнбәтнең Зөфәре исеменнән дә бу фикер тамашачыга ирештерелә: «Мәхәббәт уртак булырга мөмкин, сыныкны уртаклашырга мөмкин, әмма кешелек горурлыгын урталай бүлеп булмый икән. Кешенең үзенә куйган бәясе бар – шуннан бервакытта да төшмәячәк ул!» [2, 21 б.]. Нәкъ менә горурлык кешене түбән төшү, кимсенү, үзеңне башалардан ким сизү кебек ялгышлардан алып китә, ди Еники. Кеше үзе булдырган эшне җиренә җиткереп башкарса гына кимсенми дә, түбәнсенми дә. Зөфәр – булдыклы ир-ат, әмма, Рәшидәдән аермалы буларак, горур түгел, чөнки курка. Кешелек горурлыгын әйләнеп үткәннәргә, яшәеш тәртибен курку хисенә көйләгәннәргә тормыш-яшәеш төзәлү мөмкинлеген бирми дигән караштa тора язучы.

Рәшидә исә шул горурлыгы белән матур, көчле, үзенә тартып тора, сокландыра, гашыйк итә, хәтта үзе кебек горур булырга дәртләндерә! Рәшидә кебекләр үз гамәлләре өчен җавап бирергә әзер, андыйлар үзләренә кул салмый! Айдар Җәббаров спектакль ахырында чарасызлыктан югалып калган, куркак Рәшидә образын тәкъдим итә. Мондый Рәшидә Еникинеке түгел, тулаем режиссер уйдырмасы булып тора һәм ул тамашачыны ышандыру көченнән мәхрүм.

П. Исәнбәт сәхнәгә чыгарган спектакльдә Рәшидә образын Татарстанның халык артисты Исламия Мәхмүтова уйный. Әйтергә кирәк, спектакль куелган елны аңа Россиянең атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелә. А. Җәббаров спектаклендә Рәшидә Сафинаны Татарстанның халык артисты Гүзәл Шакирова башкара.

Зөфәрнең ваклыгын Рәшидәдәге илаһилыкны ассызыклау аша бәяләүче «әйттем-бетте» Хәмит образы кызыклы эшләнгән. Зөфәр янәшәсендәге «үз кадерен, үз дәрәҗәсен бик белә торган горур-һавалы егет» бу. П. Исәнбәт куйган спектакльдә бу персонаж үзгәрешсез, аны актер Данил Салихов башкара. А. Җәббаровның Хәмите – талантлы актер Эмиль Талиповның уңышы. Зөфәр кебекләр янында телсез-чукраклар гына була ала. Шамакайлыкны авангард мәдәнияттәге форматта бирүне режиссер һәм актерның уртак табышы һәм, һичшиксез, отышы төсендә бәяләргә кирәк.

Яруллинга Тәбрис исеме өстәү һәм аны артык заманчалаштыру тулаем А. Җәббаров җаваплылыгында булса да, актер Ф. Мөхәммәтҗанов режиссер тудырган образны талантлы эшләп чыга. Татарстанның халык артистлары Фирая Әкбәрова (Мәликә әби), Рузия Мотыйгуллина (Таибә абыстай), Әсхәт Хисмәтов (Курамшин карт), Илдар Хәйруллин (Җиһанша), Люция Хәмитова (Мәфтуха) кебек мәшһүр актерлар сәхнәгә чыгу белән, тамашачының төп игътибары шундук аларга юнәлә. 2020 елгы куелышта Әмирхан Еникидәге мәгънәне нәкъ менә алар биргән образлар берникадәр ишеттерә. Еникичә совет чоры вәзгыятенә сатира да җиткерелә (Җиһанша, Мәфтуха, Таибә абыстай), совет чорының фаҗигасе дә йөрәккә үтә (Курамшин карт), яшәеш фәлсәфәсе дә күңелгә уела (Мәликә әби).

Татар театрында Ә. Еники прозасы сәхнәләштерелү уңаеннан киң җәмәгатьчелектә бәхәсле сөйләшүләр башлануы югарыда ассызыкланган фикерне раслый ([7], [8], [9], [10], [11], [12], [13], [14], [15], [16], [17]).

Г. Куклис «Рәшә» повестен «Литературная газета»да күтәреп чыккан елны Әмирхан Еники иҗатының таҗы булырлык «Гөләндәм туташ хатирәсе» романтик повесте (1975) дөнья күрә. Повестьның язылу максатын әдип «…Салих Сәйдәшевнең яшь кенә кызны Кәрим Тинчурин, Солтан Габәши, Фатих Әмирханнар даирәсенә алып керүен күрсәтү иде» [18, 5 б.], – дип тәгаенли. Режиссер Рәшит Заһидуллин һәм Илһам Гали 2018 елда әдипнең тууына 110, бөек композитор Салих Сәйдәшевнең тууына 120 ел тулу уңаеннан повесть нигезендә спектакль эшләп тәкъдим итәләр. Авторлар бу әсәрне сәхнәләштерүгә алынуларының максатын әсәрнең кульязма нөсхәсенә кереш сүз итеп теркәп куялар: «Халык күңелендә җырга үрелгән әсәрләр бихисап, чөнки аларда укучыны, тамашачыны җәлеп итәрлек, моң ярылып ята. Ә татар моңы ул – күңелләрне айкап чыгардай, иң биек шарлавыктан түбәнгә очкан су тамчысыдай синең йөрәгеңә килеп кадалырдай көчкә ия. Ул синең янында! Татар халкының бөек улы Салих Сәйдәшевнең беренче мәхәббәте турында язылган, күпләрнең өстәл китабына әйләнгән Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» әсәрендә дә моң ярылып ята. Бу классик язучы тарафыннан бөек композитор турында язылган бердәнбер һәм кабатланмас матур әсәрләрнең берсе. «Гөләндәм туташ хатирәсе» еллар чоңгылында үз укучысын тапкан кебек, күпсанлы тамашачылар соравы буенча куелган әлеге спектакль дә, һичшиксез, үз тамашачысын табар. Иң чиста

саф хисләргә корылган мәхәббәт тарихы үзенең аһәңе, яңгырашы, куелышы белән тамашачыны җәлеп итәр» [3, 1 б.].

Күренгәнчә, язучының һәм режиссер белән инсценировка авторының максатлары уртак. Мәгълүм булганча, әсәр Фатимаи-Зөһрә исемле туташ истәлекләренә нигезләнеп язылган. «Әдипнең кулына уналты биттән торган кондәлек дәфтәре килеп керә. Аны кайчандыр Казанда яшәгән, соңыннан Ташкент шәһәрендә гомер кичергән бер яшь кыз яза. Башта кулына төшкән истәлек дәфтәрен кире кайтарып биргән булса да, Ә. Еники, еллар узганнан соң, Ташкентка барып, дәфтәрне эзләп таба. Бу вакытта аның авторы Фатимаи-Зөһрә инде вафат булган була. Истәлек дәфтәре Әмирхан Еники тарафыннан Салих Сәйдәшев музеена тапшырыла» [18, 5 б.]. «Салихның ул кыз белән яратышуын белгән бер генә кеше дә табылмады» [18, 5 б.], – дип яза әдип соңрак.

Инсценировкада С. Сәйдәшевның Гөләндәмне зыялы шәхесләр дөньясына алып керү сызыгы алга куелмый, яшьләр арасындагы кичерешләр сызыгы тарихын сөйләү үзәккә чыга. *«Зәңгәр күзле, мәрмәрдәй ак маңгайлы»* ачык йөзле, *«акыл сатарга, күп сөйләргә яратмый торган»* [19, 398 б.] егетне актер Зөлфәт Закиров уйный.

Спектакльдә өлкән Гөләндәм (Әлфия Хәсәнова) яшь Гөләндәм (Резедә Сәләхова) тарихын искә төшерә. Романтик кичерешләр сызыгы кич вакытын һәм моңсу шомлы көз фасылын символлаштыру белән башланып китә. Интертекстуальлек (С. Җәләлнең «Дим буенда», «На заре туманной юности», «Яз да була», «Туган тел», «Хәмдия», «Казан сөлгесе», «Эрбет», «Тәфтиләү», «Агыйдел каты ага», «Сибелә чәчәк» җырлары, К. Тинчуринның «Соңгы сәлам» драмасы, «Сакмар» көе, «Тукай маршы», «Мәдинәкәй» җыры, «Аккош маршы») әсәрнең буеннан-буена укучыны шул эчтәлек дулкынына көйләү алымы булып тора. Инсценировкада кайбер көйләр төшеп калса да, спектакльнең эчтәлегенә хилафлык килми.

Әсәрнең сәхнәләштерелгән вариантында романтик кичерешләр сызыгы повестьтагыча үзгәрешсез бирелә. Вакыйгалар барышында Салихның Гөләндәмне наз тулы чынбарлыкка сак кына алып керүе тасвирлана, кичерешләр сызыгы беренче романтик саф хисләр тарихын сөйләү кебек алып барыла. Автор бөек татар композиторы образы ярдәмендә камил рухлы, җитди карашлы татар егете рухи халәтен тергезә.

Повестьта беренче бүлектә гашыйк кызның кичерешләренә «нәфислеккә омтылыш» теләге салына. Нәфислек кешенең ана телендә уйлау, сөйләшү әдәбендә чагылыш таба, ди автор: *«... кулың белән уйнаганны күңелең белән ишетергә генә кирәк»* [19, 408 б.]. Ак, нәфис, җыйнак куллы Салихның уйнап күрсәткән беренче көе «Туган тел» булу (беренче исеме «Анам кабере янында» икәнлеге махсус искәртелә) очраклы түгел. Ифрат әдәпле, ихлас күңелле кыз Салих эшкәртүендәге *«гади дә, таныш та бу көйне бозмыйча-нитмичә уйнап чыга»* [19, 406 б.]. Кыз үз рухына хас нәфислекне гаҗәпләнеп, сокланып, сөенеп ача, соңрак йөрәктә туган табигыйлеккә сихерләнә, кодрәтле моң көчен – халык зарын, ачы язмышын тоя. Әйтергә кирәк, актриса Резедә Сәләхова Гөләндәм ролен гаҗәеп зыялы башкара.

Салихның үз хисләрен әйтеп бирү өлеше, («Агыйдел каты ага» тексты) яңа чынбарлыкка керер өчен, кызда кыюлык, сайлаган юлга ышаныч тәрбияләү кирәклеге турында сөйли: *«Сез каты аккан Агыйделне дә җиңел кичәрсез»* [19, 418 б.]. Көрешүгә чакыруы гашыйк Гөләндәмнең хисләрен киеренкеләндерә, асылда кыюлык һәм ышаныч өсти.

Автор Салих сөйләгән тасвирлау аша кешедәге уй-гамәл гармониясе сурәтен ясый. Татар кешесендә туган гармония – аның бәхетле-тигез тормышының матур гадәтләре, эчке моңы, ди автор. Гамәлдә шуны тергезмичә торып, татар кешесе рухи ныклыкка ирешә алмый. Шул моң татарның хөрлеге, аның җыры («Сибелә чәчәк» тексты), даими күңел халәте, кызларның театрга киенүләре үзләрендә яшәгән эти-әниләре тәрбияләгән тарлыктан милли рух табылган хөрлеккә чыгу юлына басулары кебек укыла.

Инсценировкада да шушы фикер җебен өзмәс өчен, повестьтагы Салихның беренче хәлфәсе З. Яруллинның «Тукай маршы» көен уйнавын кертү урынлы булыр иде. Салихның хәлфәсе турында бернинди ясалу-кыланусыз сөйләп чыгуы кызны сокландыра, башка дулкынга көйли, Гөләндәм Салихның Тукайны күрү-күрмәве белән кызыксына. Шул урында Салих исеменнән автор кеше күңеле омтылырга тиеш үзгә халәт – *«халык күңелендә мәңге яши башлау»* омтылышы турында әйтә:

«Күпме уй-хис бу музыкада! Олы хәсрәттән тирән әрнү бар, хәтта тәкатьсез үксү дә ишетелеп кала, әмма шул ук вакытта ул кешенең рухын төшерми, өметсезләндерми, киресенчә, аны үстерә, дәртләндерә, гүя зур-зур эшләргә канатландыра!.. Ихлас! Ә менә бу җирендә – тыңлагыз әле,

тыңлагыз». Ниндидер бер тантаналы горурлык яңгырый түгелме соң?! Тукай өчен, Тукайны тудырган халык өчен горурлык – ишетәсезме Сез шуны» [19, 458 б.].

Димәк, үз халкың белән горурлану хисләре һәр кешенең күңел таләбе, үз асылын табуга, тануга юл булып яңгырый.

Инсценировкада И. Гали, милли проблематиканы калкуландыруга әһәмият бирмәсә дә, билгеләп үтик. Ә. Еники татар кешесенең рухи ныгуын тел, дин, мәдәнияткә тартылганлык, шәхесләр даирәсе белән аралашуып яшәүгә бәйли. С. Сәйдәшевның кызны шәхесләр даирәсенә алып керү мотивы бөтенләй төшеп калган. Гөләндәмнең Фәйзи Биккинин, Мансур Мозаффаров, Солтан Габәши, Кәрим Тинчуриннар белән танышуы – Салих чакырган хөр рухлы, матур чынбарлыкка аяк атлавы ул. «Шәрык кичә»сенә әзерләнү, кичәдәге чыгышлар кызга бу рухны ныгытырга, яратырга мөмкинлек тудыралар. Салих белән башкарган «Мәдинәкәй» җыры – мәхәббәт көче, аның башкаларга тәэсире турында сөйли. Шул вакыйгадан соң Салихның Гөләндәмгә иң саф, иң мөкатдәс хисләрен әйтүе, ачылуы очраклы түгел. Чөнки Гөләндәм татарның җитди шәхесләрен күрә, аларның галилеген тоя, гадилегенә таң кала, шулай рухи ныгый. Инде саф-ихлас кыз бала үзе кебек чиста күңелле егетнең садә хисләрен кабул итәргә әзер. Еникинең Салихы –сөйгән ярына, эше-гамәленә, ниһаять, газиз халкына үтә дә сак һәм зыялы караштагы камил инсан образы.

Безнең карашка, кызның Ф. Әмирхан белән очрашуын булса да kертү мәслихәт булгандыр, чөнки инсценировка буенча яшь Салихның бөек композитор булып китәчәге ышандырмый, рухы Ә. Еники тудырган Салих Сәйдәшев рухына тәңгәл түгел урыннар бар, спектакльдәге образ садә күңелле романтик егет образыннан ерак китә алмаган кебек тәэсир кала. Әдип үзе билгеләп үткәнчә, повестьта көндәлектәге фактлар бозылмаган бит [19, 5 б.], тексттагы вакыйгаларны тамашачыга җиткерү инсценировканы мәхәббәт тарихы буларак кына кабул итүдән алып китәр иде.

Повестьның үзендә милли проблематиканы иҗтимагый мотивлаштыру әсәрдә пейзаж бирелешенә салына, «чыкылдап торган татар оясы Печән базарында» – «Евангилистовский белән Захарьевский чатында зур гына ак чиркәү, вак кына мәчетләр» шул эчтәлекне укырга әзерли. Салихның чиркәү янына җыелган гарип-гораба саилчеләргә карап торуы авторның укучысы ярдәмендә чынбарлыкка бәясе кебек укыла.

Алай да инсценировка авторы аерым бер урыннарга басым ясауны кирәк таба. Әйтик, кыз белән егетнең дин турында сөйләшүләре матур тотып алынган: *«Тик безнең мәчетләр генә музыкадан мәхрүм. Шәригать дигән нәрсә мәчеткә курай белән сорнайны гына керткән булса да, дин әһелләре музыкага бу кадәр тискәре карамаслар иде. Ә шуның аркасында без күпме артта калдык»* [19, 466 б.]. Әсәрдәге сакраль / профан каршылыгын оештырган, берникадәр экзистенциаль төсмер белән баетылган азан көе деталенең мәгънәсенә әһәмият бирү аша автор кешенең бу дөньядагы тормышын мәгънәле үткәрергә тиешлеген ассызыклый кебек:

«Гаҗәп сагышлы, моңлы ишетелә шул чакта кичке азан! Гүя фани дөньядан аера ул сине, уйлар, өметләр – барысы да бик кечерәеп кала. Тик соңыннан гына бик ямансу булып китә, тизрәк үзебезнең шул гөнаһлы дөньяга әйләнеп кайтасы килә… Дөнья кызыклырак бит, Гөләндәм!» [19, 466 б.].

Салих белән очрашу, татар көйләре серенә уралу, мәхәббәтнең көчен тою – Гөләндәм-Гөлгенәне бәхетле итә. Повестьта *«мәхәббәт ул – кешенең үзенә дә әйтергә кыймаган сере»* [19, 452 б.] дигән автор карашы Салихның кызга сер итеп Гөлгенә дип дәшүе аша җиткерелә. Инсценировка текстында исә сернең сакральлеге кими төшә, аеруча Гөлгенә дип гел кабатлап торган Салихта тамашачы зыялы, сөеклесенә карата бик сак, үтә дә җитди гашыйк мөгаллим Салих образын танымый. Салихның аерылганда уйнаган «Аккош маршы» да инсценировкада урынлы яңгырар иде.

Инсценировкада рухы сынган, тәкъдиренә буйсынган, язмышы белән килешкән кызны гомерлек үкенеч көтүе уңышлы бирелә. Эпилогка урнаштырылган автор сүзләре шул хакта сөйли. Ә Еники, кеше бары үз хисләрен яклый алса, үз рухына туры килмәгән чынбарлыкка каршы төшә алса гына, гармониягә ирешә, үзен бу дөньяда хөр һәм бәхетле хис итә, ди. Р. Заһидуллин һәм И. Гали бу фикерне җиткерүгә ирешәләр.

Шулай да повестьларны сәхнәләштергән авторлар Еники үткәргән яшәеш фәлсәфәсен тамашачыга җиткерүгә тулаем ирешкәннәр дигән нәтиҗә ясау ялгыш булыр. Алар тарафыннан әдип XX йөз башы прозаикларынннан кайтарган символлаштыру, психологизмның аң агышы кебек алымнары

эченә яшергән мәгънәләргә җитди әһәмият бирелмәгән. Еш кына спектакльләр мәхәббәт тарихын тасвирлауга кайтып кала, «Рәшә»нең соңгы куелышы исә гомумән азгын кешенең түбән хисләренә өстенлек бирә. Шуна күрә зәвыклы тамашачы нибары әдипнең теленә соклана яисә Еникине болай укуга гарьләнә. Әсәр инсценировкасындагы тайпылышларга үз мөнәсәбәтен белдереп, Казан федераль университеты доценты, әдәбият белгече М. Хәбетдинова кире рецензия язып чыга [14].

Фәридә Исмәгыйлеваның «Тормыш корабы» инсценировкасы да шул эздән китеп эшләнгән. Ә. Еникинең «Шаяру», «Тынычлану», «Төнге тамчылар», «Матурлык», «Бер сүз», «Мандарин сатучы» хикәяләрендәге мәхәббәт тарихларыннан алынган образлар язучы әсәрләрендәге репликалар ярдәмендә инсценировка авторы идеясен белдерәләр. «Тормыш корабы» Ә. Еникинең хикәяләрендәге мотивлар буенча түгел, ә образларга һәм аерым җөмләләргә таянып иҗат ителгән. Аның үзәгенә «Шаяру» хикәясендәге Диләрәнең азгынлык тарихы, Хәлил Ишмаев һәм Гасыйм Сәлаховичның котылгысыз мескенлеге чыгарылган.

Язучының «Шаяру», «Төнге тамчылар», «Матурлык», «Бер сүз» хикәяләрендә мәхәббәт, саф хисләргә ымсыну тарихы алга куела. «Тынычлану»да, «Мандарин сатучы»да кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә өстенлек бирелә. Әгәр Ә. Еники мотивлары буенча эшләнгән булса, бу спектакльдә үзәккә яратуны яшәеш фәлсәфәсе буларак аңлату алга куелыр иде. Авторга «Төнге тамчылар»дагы романтик Ләйлә хисләрен «Шаяру»дагы Диләрәгә утырту ни бирә? Ә. Еникидә Ләйлә – сөйгән ярын һич тә оныта алмаган, әмма өлкән яшьтәге ирнең исерек икәнлеген күреп, аны кыерсытмыйча гына кире кага алган саф-садә ханым. Диләрә исә – үзенең яшьлегендәге ялгышы өчен гөнаһсыз егеттән үч алу юлына баскан, назга, ратуга сусаган азгын ханым. Еникинең Ләйләсендәге сүзләрне мондый Диләрәдән әйттерү тамашачыны ышандырмый билгеле: «… әсәр Әмирхан Еники биеклегенә килеп җитә алмый, ул гына тудырган ифрат нечкә мөнәсәбәтләр, кешенең рух халәте кайдадыр томан эчендә югала кебек. Бәлки, алты әсәрне берьюлы алып, алардагы геройларның язмышларын кушу-алулар белән катлауландыру шуңа китергәндер» [20]. Нәтиҗәдә, Хәлил Ишмаевның шәхси фаҗигасе Еникидәге тирәнлеген җуя. Ирнең сөеклесе дә тормыш корабында аның кебек югалып калган мескен халәтендә сурәтләнә. Ә. Еникинең Хәлиле исә горурлыгы белән илаһи Ләйләне оныта алмый, нәкъ менә шундый романтик дастанга аллюзия итеп бирелгән хатын-кыз идеалы гомер көзендә ирне үкенергә, ялгышын танырга мәҗбүр итә. Чарасызлыктан һәркемгә үчле ханым булып әверелгән Диләрә ирне үкенечкә китерә алмас иде, һәрхәлдә, ир бөтен җаны-тәне белән янәдән аңа омтылмас иде. Ә. Еники әсәрләрендә ярату ул – кешенең тормышын тамырдан үзгәртә алырлык көч! Садә һәм илаһи хатын-кыз ир кешенең гомерлек рухи таянычы, кайчак үкенече. «Бер сүз» хикәясендәге гаплади хатын-кыз Нина да – горурлыкны матурлык итеп үстергән образ. Спектакльдә аның кимсенүе әйтелә, кабатлана, әмма тамашачы аны горур дип түгел, исерек иргә түзеп яшәгән, шуңа беренче карашка тоелган ирнең назына ымсынган бичара хатын буларак истә калдыра. Болар хикәядәгечә, әмма инсценировкада акцентлар башкача куелган.

Ә. Еникинең Мәрвәр ханым образы да инсценировкада артык түбәнәйтелгән. Хикәя тексты буенча ул ирен көчләп диярлек өйләндерә, әмма көйләп, ихтирам итеп яши. Ә спектакльдәге Мәрвәр «Саз чәчәге»ндәге Майпарвәзне хәтерләтә:

> «Рәхәтләнеп йокламыйча нишли торгансыңдыр, төне буе да әйләнеп-тулгандың. Болары нинди этрәк-әләмнәр, нәрсә дип сөйләшәсең алар белән. Җыен иләс-миләс белән бәйләнгәнче, файдалы кешеләр белән аралашырга кирәк, җаным. Әнә теге Семен Семенович дигәне – яши белүе күренеп тора. Теплоходны үз товары белән шыплап тутырган, Каф тавы кадәр. Күңел ачарга хатыннар эзләп йөри әнә. Хатыннар димәктән, теге син яшь чакта селәгәеңне агызып йөргән Диләрә дә монда икән. Бик һавалы, ире аркасында әллә кем булып кылана, баштанаяк киенгән-ясанган. Ире бик начар икән» [4, 3 б.].

Ә. Еникидәге Мәрвәр ханым иренең аны яратмавын, башканы оныта алмавын белә, әмма аны кимсетми, түбәнсетми, йөрәк ярасын эчтән кичерә, гаиләдә гауга юк. Еникинең Мәрвәре ул – ханым – үзе сайлаган язмыш белән килешкән горур хатын, спектакльдәге персонаж исә – ирен түбәнсетеп яшәүче, аны салып таптаган, асылда бик бәхетсез тупас хатын.

Спектакльдәге Сукыр тамгалы персонаж – инсценировкада уңышлы уйлап табылган, Ф. Исмәгыйлеваның Ә. Еникине укып әйтергә теләгән фикерләрен читләтеп әйтеп бирүче образ. Асылда, ирлек горурлыгын тәмам салып таптаган бичара Гасыйм Сәләховичның да,

